Шәһри КАЗАН

СИШӘМБЕ, 29 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 11 (5189)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

6 бит

«КАЗАН ЧОРМАСЫ»НДА НИЛӘР БУЛМАС...

8 бит

КАН ТАПШЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ ЯҢА ТӘРТИПЛӘР

9 бит

«АЙДАР АГАДАН СОҢ ГЫНА...»

КӨН АВАЗЫ

Казанда коррупциягә каршы көрәшүче полиция хезмәткәре ришвәт биргән. Тикшерүчеләр ЭЭМның Татарстан буенча икътисади куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору идарәсендә бүлек җитәкчесе булып эшләүче 43 яшьлек бер ханымга карата җинаять эше ачкан. ЮХИДИ хезмәткәрләре юлда бер ир-атны туктатып, аның документларын тикшергән. Аның машина йөртү хокукы башка кешегә теркәлгән булган һәм юл йөрү таныклыгында ялган документ билгеләре дә күзәтелгән. Ә ханым исә ир-атка ярдәм итәргә һәм әлеге дә баягы таныклыкны алырга теләп, ЮХИДИ инспекторына кырык мең сум акча тәкъдим иткән.

* * *

Бразилиядәге Санта-Мария шәһәренең бер төнге клубында узган дискотекада янгын чыккан. Ике мең кешене сыйдыра алган клубның бер генә чыгу юлы булган. Соңгы мәгълүматларга караганда, анда 233ләп кеше вафат булган. Тагын 117 кеше янгын вакытында бүленеп чыккан агулы газдан зыян күргән. Тикшерүчеләрнең сүзләренчә, «Кисс» клубының янгын сүндерү лицензиясенең вакыты да август аенда ук гамәлдән чыккан. Әлеге уңайдан Бразилиядә өч көнлек матәм көне игълан ителгән.

* * *

Чәйгә бәяләр артырга мөмкин. Чәй җитештерүче илләр үзләренең оешмаларын – Чәй җитештерүчеләрнең халыкара форумын булдырырга тели. Форумга керүчеләр үз продукцияләрен сатуга квоталар кертергә уйлый. Шуңа да, экспертлар фикеренчә, дөньяда иң популяр саналган эчемлеккә бәяләр сизелерлек артачак. Оешмага Шри-Ланка, Һиндстан, Индонезия, Малави һәм Руанда кебек илләр керәчәк.

УНИВЕРСИАДА ҖИҢҮЧЕЛӘРЕНӘ — ЛАЛӘ ЧӘЧӘГЕ

2 бит

Дамир БӘДРИЕВ фотосы

КАЗАНГА КҮП САНДА ЭШЧЕЛӘР КИРӘК

«ШК» газетасының 31 гыйнвар — пәнҗешәмбе санына алхәбәр

«Кеше машинам яңа дип тәмәкене урамга чыгып тарта. Ничек 600 меңлек машинаңа тәмәке исе сеңдерәсең инде? Әле 3 ел буе кредитын түлисең. Ә саулык күктән төшкән, бушка килгән...»
Йосыф ДӘҮЛӘТШИН. «Патшалык күпме тора?»

7 бит

Максуд Юлдашев: «Күптән түгел генә «Бродвей» төркеме белән эшли башладым. Миңа кадәр әлеге төркемнең солисты «Голос» телевизион конкурсында беренче урынны яулаган Динә Гарипова иде».
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. «Мин эколог булырга тиешле кеше»

9 бит

«Кызлар, әниләренең ике бүлмәле фатирын саттырып, әтиләренә бер бүлмә алып бирәләр. Үзләренә дә аннан өлеш чыгаралар. Әниләренең язмышы гына борчымый үзләрен. Надирә урамда кала».
Люция ХӘБИБУЛЛИНА. «Әниләрен урамда калдырдылар»

11 бит

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Тәлгать АБДУЛЛИН,
ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды башкарма директоры:

— Киленне ачуланырга кирәк булганда, кызны орышалар. Килен ишетсен дип...
(«БИЗНЕС Online» укучылары белән булган интернет-конференция вакытында әйткән сүзләре)

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Инноваторларны тәрбияләргә кирәк

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов Республика яшьләр форумы-2012 җиңүчеләрен котлады.

IT-лицейда узган чарага федераль конкурс мәйданчыкларында җиңүчеләр, ТР махсус дәүләт стипендиясен алучылар, ТР Дәүләт Советы, ТР Президенты Аппараты, ТР Министрлар Кабинеты, республика министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре, вузлар ректорлары һ.б. чакырылган иде. «Сезнең даирәгә эләккән саен, уңай эмоцияләр алабыз һәм республикабыз һәм илебезнең ничек үзгәрүен күрәбез», – диде Татарстан Президенты форумда җиңүчеләрне бүләкләү алдыннан. Ул, IT-лицей төзү идеясе Универсиада авылы төзелгәч туды, дип искәртте. IT-лицей мондый гамәлнең нәтиҗәле булуын күрсәтте һәм быел химия лицее ачылачак. «Казан технология фәнни-тикшеренү университеты безнең белән бергә бу мәсьәлә белән шөгыльләнә. Лидерлар, инноваторлар кирәк, алар үзләреннән-үзләре пәйда булмый, аларны тәрбияләү зарури», – дип ассызыклады Р.Миңнеханов.

23 февраль ялы майга күчә

КАЗАНЛЫЛАР һәм Татарстан халкы Ватанны саклаучылар көне хөрмәтенә ял итеп тормаячак.

Казан шәһәре мэриясенең рәсми порталы белдергәнчә, бу бәйрәм ялы май аена күчерелә. 23 февраль шимбә көненә туры килгәнлектән, канун нигезендә, ул 25 февраль – дүшәмбегә күчәргә тиеш иде. Әмма Россия Хөкүмәтенең 2012 елның 15 октябрендәге «2013 елда ял көннәрен күчерү турында»гы карары нигезендә бәйрәм ялы 25 февральдән 10 майга – җомгага күчерелә. Бу ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрен файдалырак итеп уздыру максатыннан эшләнә.

СОРАШТЫРУ

Безнең һәр көнебез диета

Британия галимнәре фикеренчә, аларда һәр өченче ир-ат ашерен рәвештә генә диетада утыра. Алар 600 ир-аттан диетада утыру-утырмавы белән кызыксынган. Сораштырылучыларның туксан проценты ябыгырга тели, әмма һәр өченчесе үзенең планы турында беркемгә дә әйтергә җыенмый икән. Ә сезнең диетага утыру турында уйлаганыгыз бармы?

Рәмис Аймәт, Тукай музее җитәкчесе:

– Һәр көнебез диета дип әйтергә була. Россиядә мәдәнният хезмәткәрләренең хезмәт хаклары зур түгел. Шуңа да әллә ни күп ашап симерү куркынычы юк.

Әбри Хәбриев, «Татар радиосы» ди-джее:

– Минем физиология шулай көйләнгән инде: көнәнә биш-алты тапкыр ашасам да, гәүдә озынлыгы белән авырлыгында пропорция саклана. Буем – 170 см, гәүдә авырлыгым – 70 кг. Миңа симерү куркынычы янамый дип беләм, шуңа диета турында уйлаганым юк. Ә Британия галимнәренең яшерен рәвештә дигән сүзе белән килешәм. Диетада утыручы ирләр дә бардыр, тик ират үзенә кагылышлы серне чишәргә яратмый бит ул.

Мөнир Кәримуллин, газета укучы:

– Диетада утырмыйм, тик бөтен нәрсәне дә авызга тутырмыйм. Бу, бәлки, үзенә күрә бер диета саналадыр. Диетага утыруның сәбәпләре төрле. Хатынкызлар диетага ябыгыр, фигурасын рәтләр өчен утыра, ә ирләр исә гәүдә авырлыгы аркасында сәламәтлеге какшый башлагач...

Казан шәһәре мэриясе, Казан шәһәре Думасы депутаты Мөслимә Хәбри кызы Латыйпованың, абыйсы **Мансур Хәбибрахман улы**ның вафат булуы сәбәпле, олы кайгысын уртаклаша, туганнары һәм якыннарына сабырлык тели.

Информация о наличии (отсутствии) технической возможности доступа к регулируемым товарам и услугам, а также о регистрации и ходе реализации заявок на подключение к системе холодного водоснабжения и водоотведения МУП «Водоканал» г. Казани за 4 квартал 2012 г.

	холодное водоснабжение	водоотведение
Количество поданных и зарегистрированных заявок на подключение	67	67
Количество исполненных заявок	67	67

Дополнительные данные по подключению размещены на сайте Комитета ТР по тарифам http://kt.tatarstan.ru/.

КАЗАН ХӘБӘРЛӘРЕ

Казанга күп санда эшчеләр кирәк

Башкалада 5329 кеше эш урынсыз буларак теркәлгән. Ләкин шул ук вакытта 16 мең урынга вакансия бар.

ВАЗГЫЯТЬ

Дамир БӘДРИЕВ

«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» учреждениесе директоры Валерий Корнеевның чыгышында әйтелгәнчә, узган ел 10 мең кеше мәшгульлек үзәкләре ярдәмендә эш тапкан. Хезмәт эшчәнлекләренә үзгәрешләр кертү сәбәпле, «ICL КПО ВС», «Нәфис Косметикс», «Хитон» акционерлык җәмгыятьләре һәм башка предприятиеләр 895 эшчесен алдан ук укытып куйганнар.

Бүген Казанда кадрлар җитмәү үзен нык сиздерә башлаган. Транспорт комитеты рәисе Айдар Абделхаков: «Автобус шоферлары кирәк. Уртача хезмәт хаклары 28 800 сум», – диде. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Азат Нигъмәтҗанов төзелеш тармагына төрле һөнәрле күп санда эшчеләр кирәк булуын хәбәр итте. Яңа футбол стадионы һәм Ленин дамбасындагы күпер төзелешләренә эшчеләр сорала. Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин: «Коммуналь хуҗалыкта 1 мең эшчегә хезмәт урыны бар. Ишегалларын җыештыру эшләренә тагын 750 кешене чакырабыз. Җыештыручыларның хезмәт хаклары 9-12 мең сум», – диде. Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе Рамил Әхмәтов сөйләгәнчә, Казанда 400 табиб урыны буш. Шәһәрнең медицина тармагы, гомумән, 30 процентка кадрлар ихтыяҗы кичерә.

Мэр Илсур Метшин: «Грециядә һәм Испаниядә яшьләрнең һәр икенчесе эш урынсыз. Бездә эш урыннары җитәрлек. Тик безнең яшьләр шунда ук банк яки предприятие директоры буласы килә. Үсмер егет вакытында үзем дә предприятиеләрдә вак эшләрдә катнаштым. Хезмәт хакыма сөенгәндем, кайбер нәрсәләргә әти-әнидән акча алмавыма шатландым. Инвалидларны, каникуллар чорында үсмерләрне хезмәт белән тәэмин итүгә зур игътибар бирелсен», – диде.

Истәлекле акчалар чыгарылды

UNIVERSIADE KAZAN 2013 RUSSIA

Россия Банкы, Казанда быелның июль аенда узачак Студентларның халыкара Универсиадасына багышлап, истәлекле акчаларны әйләнешкә кертте.

УНИВЕРСИАДА СУЛЫШЫ

3 һәм 5 сумлык – көмеш, шулай ук 50 сумлык һәм 10 мең сумлык алтын акчалар чүкелгән. Акчаларга UNIVERSIADE KAZAN 2013 RUSSIA дип язылган, Казан Кремле һәм спортчыларның сурәтләре төшерелгән. Универсиада темасына кыйммәтле булмаган металлдан да 10 миллион данәдә 10 сумлык ике төрле акча чыгарылган. Россия Банкының җәмәгатьчелек белән элемтәләр департаменты белдерүенчә, бу акчалар Россия Федерациясенең барлык җирлегендә гамәлдә һәм һәртөрле түләүләр үткәргәндә кабул ителүе мәҗбүри.

Металл акчаларның алгы ягына канатлары салынып торган икебашлы бөркет рәвешендә Россия Банкы эмблемасы төшерелгән. Эмблема астына «Банк России», ә бөҗра буенча акчаның номиналы һәм чүкеп чыгарылган елы язылган. Алар арасында металл төре, кою пробасы, Санкт-Петербург монета дворының товар билгесе, кыйммәтле металлның саф өлештәге авырлыгы күрсәтелгән.

«Казан-2013» башкарма дирекциясе» хәбәр итүенчә, акчалар озакламыйча Россия банкларына таратылачак.

Универсиада җиңүчеләренә — лалә чәчәге

БӘЙГЕ

«Казан 2013» Башкарма дирекциясе оештырган «Универсиада букеты» Бөтенроссия бәйгесенә йомгак ясалды.

Авторлар, куелган таләпләрне саклаган хәлдә, үзләренең иҗади осталыкларын да оста файдаланган. Казаннан «Альянс-флористика» осталарының «Чемпионнар букеты» номинациясенә тәкъдим иткән эше үзенең матурлыгы, зәвыклылыгы белән аерылып тора иде. Кызыл төстәге 21 кечкенә лаләдән тупланган һәм яшел төргәкле әлеге букет янып торган чын факелны хәтерләтә. Жюри беренчелекне аңа бирде. «Кунакчыллык букеты» номинациясендә Казан остасы Фирүзә Осотова композициясе җиңүче дип табылды.

Информация об инвестиционной программе МУП «Водоканал» г.Казани

Инвестиционная программа МУП «Водоканал» города Казани утверждена Решением Казанской городской Думы от 29.04.2009 №11-40 «Об инвестиционной программе Муниципального унитарного предприятия г.Казани «Водоканал» на 2010-2012 годы» с учетом изменений, внесенных Решением Казанской городской Думы № **12-19** от **27.12.2012.**

Цели инвестиционной программы: повышение надежности работы систем водоснабжения и водоотведения в соответствии с нормативными требованиями; повышение качества оказываемых услуг водоснабжения и водоотведения; снабжение сетями инженерно-технического обеспечения новых строительных площадок и присоединенных к г. Казани поселков; увеличение пропускной способности сетей водоснабжения и водоотведения.

Сроки реализации программы: 2010-2013 годы.

Объем финансирования 2686910 тыс. рублей, в т.ч. по источникам:

плата за подключение к системам водоснабжения и водоотведения 962350 тыс. рублей; инвестиционная надбавка к тарифу на водоснабжение 377060 тыс. рублей; инвестиционная надбавка к тарифу на водоотведение 433940 тыс. рублей; амортизационные отчисления – 388160 тыс. рублей; прибыль – 36200 тыс. рублей; заемные средства – 489200 тыс. рублей.

Перечень объектов инвестиционной программы:

№ п/п	Наименование объектов	Всего на 2010-2013г.г., тыс. руб.	в т.ч. по годам			
			2010	2011	2012	2013
	Водоснабжение	**1607700**	**162800**	**307200**	**502340**	**635360**
1	Реконструкция сооружений очистки питьевой воды Волжского водозабора	645160	17300	115500	300900	211460
2	Реконструкция НС-2 подъема Волжского водозабора	113500	105700	7800	0	0
3	Строительство ВУ «Тэцевский» со строительством водовода от Волжского водозабора до ВУ «Тэцевский»	251200	100	52300	100000	98800
4	Реконструкция водопроводного узла «Северо-Восточный»	234800	4800	68600	11100	150300
5	Строительство сетей и сооружений водоснабжения в жилых комплексах, в т.ч. объектов социальной инфраструктуры	229850	34400	62400	66250	66800
6	Реконструкция сетей и сооружений водопровода	24190	500	600	15090	8000
7	Строительство ВУ «Дербышки» и водовода от ВУ «Северо-Восточный» до ВУ «Дербышки»	59000	0	0	9000	50000
8	Строительство подземного водозабора в пос. Мирный	50000	0	0	0	50000
	Водоотведение	**1079210**	**301400**	**217600**	**200170**	**360040**
1	Строительство КНС «Ново-Ометьевская»	123875	108000	15875	0	0
2	Реконструкция КНС «Главная» с напорными коллекторами	2870	0	200	2670	0
3	Реконструкция КНС «Ипподромная» с напорными коллекторами	24200	0	1400	3700	19100
4	Строительство Ново-Ометьевского коллектора	122750	115500	7250	0	0
5	Реконструкция БОСК и КНС «Искож»	248500	44200	76700	46000	81600
6	Реконструкция КНС «Азино-4»	66700	4000	35900	26800	0
7	Строительство сетей и сооружений водоотведения в жилых комплексах, в т.ч. объектов социальной инфраструктуры	227675	29700	50275	84300	63400
8	Реконструкция сетей и сооружений водоотведения	135940	0	30000	36700	69240
9	Строительство КНС «Заречная» с 2-мя напорными коллекторами Д1400мм от КНС «Заречная» до очистных сооружений г. Казани	73100	0	0	0	73100
	ВСЕГО	**2 686910**	**464200**	**524800**	**702510**	**995400**

*в полном объеме информация размещена на официальном сайте МУП «Водоканал» www.kznvodokanal.ru

ҖӘМГЫЯТЬ

Язмышым юлларыураумы?

Бүген бәхетле булуны аңлыйсызмы сез? Бәлки, бәхет төшенчәсе үткән белән бәйледер дә һәм ул киләчәкнең ымсындыргыч биеклегедер?

ПРЕМЬЕРАДАН СОҢ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Әнә шундый сүзләрне К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында узган «Язмышым юллары» исемендәге музыкаль-поэтик спектакльдә ишеткәч, күпләр әсәренеп калгандыр. Мин дә, ирексездән, шуңа килеп «төртелдем». Чыннан да кичәге көн бәхетлерәк иде кебек тә, офыктагы яңа таң бүгенгегә караганда алсурак күренәдер... Кайсыбыз гына менә шушы көндә, менә шушы мизгелдә җиһан ярып: «Мин бәхетле!» – дип кычкыра ала?

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев иҗат иткән, әдипнең биографик иҗат юлына багышланган премьерада без бәхет төшенчәсенең төрле сурәтен, төрле чагылышын күрдек төсле. Әни итәгендә балачак бәхетенә кинәнү, мәхәббәт хисенә исереп, дөньяга алсу күзлекләрнең бәхетле пыяласы аша багу, ир булып өлгереп, беренче балаңны күкрәгеңә кысу ләззәте, фикер туплап, акыл утыртып, үз халкыңның игелекле улы дәрәҗәсенә ирешү, аннан аны күз карасыдай саклау. Һәм менә шушы һәр баскычта күкрәк читлегендә кош баласыдай канат ныгытучы шигъри утыңны сүндермәү, шагыйрь халәттә яшәү.

Разил абыйның ул нисбәттән язмыш юллары бәхет белән уралып барган да. Мәскәү кадәр Мәскәүдә, бернинди уңайлыгы булмаган тормыш шартлары чабудан тартып торганда да, кая анда күңел төшенкелегенә бирелү! Әнисенә «шигырьләтә» җибәрелгән кучтәнәчләрендә дә, кызына Сөембикә исемен бирүдә дә, гомер юлдашы белән тормыш мәктәбен бер булып үтүдә дә аның ирләрчә сабырлыгы, ирләрчә аксакаллыгы, шагыйрьләрчә романтиклыгы чагылып ята. Бу нисбәттән шагыйрьнең йөзләгән мәхәббәт җырлары гына ни тора. Аларны рәхәтләнеп тыңла да тыңла гына...

К.Тинчурин театрының яшь артистлары – Артем Пискунов, Лия Вильданова, Резидә Сәлахова һәм Илфак Хафизовлар, профессиональ җырчылар булмасалар да, музыкаль бизәлеш ягыннан шактый әйбәтлек белән чыктылар спектакльгә. Шагыйрь Разил Вәлиевнең иҗатын ачып бирергә, аны тамашачы күңеленә бәхет тәме итеп салырга тырышты алар. Ә без – тамашачы исә кабат шагыйрь иҗатын алар белән бергәләп сүттек тә, әдип иҗатының саллы һәм бәхетле икәненә инандык.

Татарча да яхшы бел

БРЕЙН-РИНГ

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Һәр чорның, һәр заманның үз таләбе. Бүген инглиз телендә сөйләшә-аралаша алсаң, бер башка югары буласың. «Күпме тел беләсең, син шул мәртәбә кеше» дигәнме әле Антон Чехов?! «Татнефть» ААҖдә инглиз теленә, дәресргәге, техник инглиз телен белүгә зур игътибар бирелә. Бу яшь белгечләр конкурентлык сәләтенә ия булсын һәм чит илләр әдәбиятын укып, үз практикаларында куллана алсын өчен эшләнә. Тел чарлауны күздә тотып, яшьләр арасында да инглиз телендә брейн-ринглар үткәрү әлеге компаниядә күркәм традициягә әйләнде.

«Баулынефть» идарәсендә узган брейн-рингта өчәр кешедән торган 22 команда катнашты. Телне камил беләм дип уйласаң да, үзеңне башкалар янәшәсенә куеп сынап карагаңда, әлбәттә, каушыйсың. Команда белән ярышу да, бер карасаң, ышанычны тудыра, шул ук вакытта синең башкалар алдында да җаваплы икәнлегеңне искәртә.

Ярышларның бөтен асылы да шунда – коллективны, бердәмлекне тою да, тәҗрибә уртаклашу һәм аралашу да инде.

«Инглиз телендә брейн-ринг уены» формасында үткән ярышларда «Елховнефть» идарәсе, нефть һәм нефть продуктларын сату идарәсе, «ТатНИПИнефть» институты һәм «Главнефтегазстройсервис» идарәче компаниясе яшь белгечләре җиңде.

Тарихи ядкарьләр саклауга мохтаҗ

МИРАС

Люция ГАЛИМҖАНОВА

«Бүгенге көндә тарихи объектларны саклауга караш үзгәрде», – дип башлады үзенең сүзен мәдәният министры урынбасары Светлана Персова журналистлар белән узган матбугат конференциясендә. Аннары ул 1500 бинаның дәүләт саклавында торуын әйтеп узды. Светлана Глебовна билдергәнчә, хәзерге вакытта 114 объектны саклау юнәлешендә эш алып барыла. Мәскәү районындагы дүрт объектка шәхси эшмәкәрләр җәлеп ителгән. Иске Татар бистәсендәге агач ядкарьләрне инвесторлар ярдәме белән торгызу күздә тотыла.

Мәдәният министрлыгының һәйкәлләрне саклау буенча идарәсе каршындагы оешкан мәдәни мирас үзәге узган елның ноябрендә эшли башлады. Аның җитәкчесе Илзирә Кузьмина үзләренә шактый зур бурычлар йөкләнүен яхшы аңлый. Быелдан ул фәнни проектлар ачарга җыена. «Мирас» программасы 1916 елга хәтле әлеге юнәлештәге эшчәнлекләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатыннан, журналистлар арасында конкурс та игълан итте. Ул «Югалып баручы Казан» һәм «Татарстанда мәдәни мирасны саклау» төрләрендә быелның 31 мартына кадәр узачак.

Тар күңелләләр — без түгел ул

КАРАШ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
Балтач

Россиянең беренче тапкыр үткәрелгән «Голос» телепроектында Татарстанның татар кызлары җиңеп чыгу уңаеннан безнең матбугат бәйрәм итте дә соң! Миллилегебез, милли хисләребез тоныкланды, дигән булабыз тагы, аны балкытып җибәрергә бер матур сәбәп, бер якты нур гына җитмәгән икән бит. Ике кызыбызның берьюлы көтелмәгән зур уңышка ирешү нур өстенә нур булды менә. Уңышлы чыгышларның алдагы иртәсендә үк Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллинага Татарстанның атказанган артисты исеме бирелү дә шәп килеп чыкты, минемчә (кызларның фатир белән дә бүләкләнүе соңрак мәгълүм булды). Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның бу гамәле сөенердәе. Әйе-әйе, бу очракта кызлар өчен генә түгел, нәкъ менә Президент өчен дә куандык без, дип уйлыйм. Россия бәйгесендә җиңгән, үсә калсалар (бирсен Ходай!), урыс җырчылары буларак кына танылу ихтималлары зур булган кызларның киләчәк тормышларына һәм иҗатларына Татарстан биргән мактаулы исем кирәк булырмы-юкмы, әйтүе кыен, ә менә милләттәш сеңелләр өчен ихлас сөенеп, аларга җылы тәбрикләү сүзләре әйтүе, бүләкләр тапшыруы Рөстәм әфәнде Миңнехановка бик тә кирәк иде, диясе килә. Артык сиздерергә теләмәсәк тә, без дә әкрен генә миллиләшә бара торган татар баласы һәм бездә дә миллы терәк-таянычларга ихтыяҗ зур ләбаса. Узган елгы хәвефле, күңел төшерә торган хәлләрдән соң рухи-милли таянычны, яхшылык-яктылыкка таба бер маякны һәрберебез бик тансыклаган да булганбыз икән бит.

Ләкин милләттәш сеңелләрнең искитәрлек уңышы һәммәбезне диярлек сөендерсә дә, аларга төрле-төрле бүләкләр тапшыру җәмгатьчелектә бертөрле генә фикер калдырмады кебек. Интернет сәхифәләрендә Татарстан җитәкчелегенең әлеге гамәленә тискәре караш бигрәк тә көчле, дип ишетәбез.

АХЫРЫ 9 НЧЫ БИТТӘ

АЙНУР ГАЛИМОВ

Заманчалашкан машина йөртүчеләр

«Таныклыгыгызны күрергә мөмкинме?» Шушы сорау белән башлыйлар үзләрен туктаткан юл полициясе хезмәткәре белән сүзне бүгенге көндә үз хокукларын яхшы белгән машина йөртүчеләр. Канун вәкиле исә, шоферның беренче соравы буенча, таныклыгын чыгарып күрсәтергә бурычлы. Машина сөючеләрнең күбесе, юл патруле хезмәткәрләре белән аралашканда, үзләрен иркен тота хәзер, сырлы-сырлы, аклы-каралы таяк болгауларын күрүгә коелып төшү заманасы артта калып бара.

Юл патруле хезмәткәре, таныклыгын күрсәтү зарурлыгыннан тыш, туктату сәбәбен анык итеп аңлату, машина йөртүче белән әдәпле итеп сөйләшү, тыныч һәм сабыр булу, үзенә дорфа эндәшсәләр дә, дорфалык белән җавап бирмәү; административ җаваплылыкка тарткан очракта, юл кагыйдәләрен бозучыга аның бурычларын һәм хокукларын аңлату кебек гамәлләрне дә башкарырга тиеш. Болар барысы да РФ Эчке эшләр министрлыгының 1999 елның 20 апреле көнне кабул ителгән боерыгында акка кара белән язылган.

Соңгы елларда кешенең шәхес буларак хокуклары үтәлүгә игътибар арту һәм һәммәбезнең үз хокукларыбызны яхшы белә башлавыбыз белән барысы да үзгәрде. Мисал өчен, элек тизлекләрен арттырып баручылар, куаклар арасыннан таягын болгый-болгый абына-мәтәлә каршыларына йөгереп чыккан ДАИчыны күрүгә, шып итеп туктыйлар һәм калтыранган куллары белән акча әзерли башлыйлар иде. Хәзер әлеге ситуациядә машина йөртүче андый юл патруле хезмәткәре яныннан выжылдап узып кына китә, чөнки махсус машинасыз ДАИчы ДАИчы түгел дигән канун бар. Андый очракта безнең бердәнбер дөрес гамәлебез – якындагы ДАИ посты янына туктап, юлда полиция формасы кигән ниндидер шикле кеше күрдем, дип хәбәр итү яки, өйгә кайткач, җирле ДАИ башлыгы исеменә, хәлне аңлатып, гариза язу. Кем белгән, махсус буяулы һәм утлы машинасы булмаган (кулары артында машинасы торса да, без аны күрмибез бит) ул форма кигән зат «погонлы убырдыр» бәлки? Хәер, хәзер юл патруле хезмәткәрләре үзләре дә куаклар артында утыру гадәтеннән баш тарттылар бугай инде.

Әйткәнемчә, машина йөртүчеләрнең күбесе үзләренең Конституциядә һәм Гражданнар Кодексында теркәлгән хокукларын яхшы беләләр һәм, шул ук юл полициясе хезмәткәрләре ул хокукларны бозарга җөрьәт итсә, дәлил булсын өчен, машиналарына видеокамералар да беркетәләр. Бу эш – юлларда ришвәтчелек чәчәк атмасын өчен дә нәтиҗәле чара.

Интернет челтәрендә юл патруле хезмәткәрләре белән аралашуны төшергән видеоязмалар бихисап. Ул язмалардан күренгәнчә, гадәттә, видеога төшергәннәрен күргән «юл хуҗалары» үзләрен бик җыйнак тоталар, әдәпле итеп сөйләшергә тырышалар. Элегрәк еш күзәтергә мөмкин булган ихтирамсыз мөнәсәбәт, боерык тоны белән сөйләшү, басым ясаулар юк. Машина йөртүче үзен туктатканда, аралашу барышында, салон эчендә һәм багажникта тикшерү яки тентү үткәрү гамәлләрендә хокукларын бозуны сизеп алып, ДАИчының бурычларын һәм үзенең хакларын саный башласа, юл патруле хезмәткәре андый белдекле шофер белән бәйләнешеп тә тормый, куп очракта, «Хәерле юл» теләп, юлын дәвам иттерүен генә сорый.

Машинага беркетелгән видеокамера язмаларыннан күренгәнчә, машина йөртүчеләр, юл патруле хезмәткәрләре белән аралашканда, канунда язылган шушы моментларга басым ясыйлар: инспекторның әдәпле сөйләшүе һәм сорагач та, таныклыгын күрсәтүе, туктату сәбәбен анык итеп аңлату һәм төпле дәлилләре булу, беркетмәне шаһитлар барында төзү, машина эчен тикшергәндә яки тентү ясаганда, махсус рөхсәте һәм шулай ук шаһитлар булу. Болардан тыш, кайбер артык белдекләләренең радарның номерлары аның документындагы номеры белән тәңгәл килүе, тәрәзәнең караңгылыгы дәрәҗәсен үлчәүче приборның һәм алкотестерның сертификатлары булуы кебек ваклыкларга бәйләнеп утырган видеолар да бар.

Тик алай артыгын кылану да кирәк түгел. Юлларда ДАИ инспекторларының тәртипсезлеге белән көрәшергә алынгансың икән, үзең дә гадел, намуслы бул, юл хәрәкәтенең башка катнашучылары, җәяүлеләр белән исәпләш, юл кагыйдәләрен бозма. Һәрбер гамәл каршы гамәл тудырганын онытырга ярамый – «батыр» машина сөючеләргә моны да истән чыгармаска киңәш итәр идем.

ИКЪТИСАД

Россия әле һаман үзенең ВТОның тулы хокуклы әгъзасы булуына ышанып җитә алмый

Заманыбызның иң җор телле сәясәтчесе Виктор Черномырдин кайчандыр: «Как только мы начнём куда-нибудь вступать – обязательно на что-нибудь наступим», – дигән иде. Кызганыч, һаман хаталардан сабак алып бетермибез шул.

Бөтендөнья сәүдә оешмасының иң югары органы – Министрлар конференциясе җыенында Россияне бу абруйлы клубка алулары турында документ кабул ителүгә бер елдан артык вакыт үтте. Ахыргы карар кабул ителү турындагы документның Россия парламентының түбән һәм югары палаталарында расланып, илебезнең әлеге халыкара оешманың тулы хокуклы әгъзасына әйләнүенә дә ярты ел булды инде. Тик Россиянең гамәлләре әле һаман үзен ВТО әгъзасы итеп тоймавын раслый. Бу проблема шушы көннәрдә Мәскәүдә узган традицион Гайдар форумында да күтәрелде. Дөньяның әйдәп баручы финансчылары һәм икътисадчыларын җыйган әлеге дискуссия мәйданында глобаль интеграция шартларында Россиянең көндәшлеккә сәләтенә, аның Бөтендөнья сәүдә оешмасы әгъзасы буларак адымнарына аерым урын бирелде.

Бөтендөнья сәүдә оешмасы генераль директоры Паскаль Лами, Россия түрәләрен эшлексезлектә гаепләп, илне ВТОның тулы хокуклы әгъзасы итеп тоймауларын, әле һаман әгъзалыкка кандидат итеп фикер йөртүләрен кискен тәнкыйтьләде. Шактый еллар дәвамында ВТОга керү буенча сөйләшүләр алып баруда актив катнашучыларның берсе булган Россия Саклык банкы президенты һәм идарә рәисе Герман Греф та ВТО генераль директорының позициясен хуплый. Россиянең үзен һаман Бөтендөнья сәүдә оешмасының тулы хокуклы әгъзасы итеп сизмәве нәтиҗәсендә әлеге оешманың норма һәм кагыйдәләренә кагылышлы гади генә мәсьәлә дә хакимиятне кыен хәлдә калдырырга мөмкин, дип кисәтә ул.

Ә шул ук вакытта Бөтендөнья сәүдә оешмасына кушылуның Россия өчен уңай һәм тискәре нәтиҗәләре хакында дистә ел дәвам иткән бәхәсләр һич тынмый. РФ Президенты Владимир Путин ВТОга кушылуның Россия өчен барыннан да бигрәк сәяси мәсьәлә булуын әйткән иде инде. Бүген бер нәрсә ачык: заманча нәтиҗәле икътисад төзергә һәм дөнья сәүдәсендә тигез хокуклылыкка ирешергә теләгән һәр ил ВТО әгъзасы булырга омтыла. Россия дә моннан читтә кала алмый, билгеле. Тик яңа шартларда ил җитештерүчеләрен нинди язмыш көтә дигән сорауга әлегә анык кына җавап юк. Бер як, дөнья базарында конкурентлык таләпләрен исәпкә алып, Россиянең икътисади-сәүдә багланышларына уңай йогынты ясалачак, безгә чит ил инвестицияләре килү артачак, дип белдерә. Икенчеләр исә, икътисадның кайбер секторларының көндәшлек дәрәҗәсе түбән, шуңа ВТО кысаларына керергә ашыкмаска иде, дигән фикердә. Бөтендөнья банкының бу уңайдан үз фикере: ВТОга кушылу Россия икътисадын урта вакытлы перспективада – 3,3, озак вакытлы перспективада 11 процентка кадәр үстерергә сәләтле икән. ВТО әгъзасы буларак, Россиягә читтән кертелә торган дарулар, компьютерлар, көнкүреш техникасы, парфюмерия, косметика, мебель, туннар һ.б. товарларның хакы 10-15 процентка арзанаю фаразланган иде. Бу импорт пошлиналары киметелүгә бәйләнгән. Кайбер төр товарлар буенча Россиядә импортның өлеше 40-60 процентка җиткәнен күздә тотсак, бәяләр төшү кулланучы өчен файдага гына булыр кебек иде. Тик мәсьәләнең икенче ягы бар: ВТО шартларын кабул иткән Россия читтән кертелүче товарларга таможня пошлиналарын киметүгә генә түгел, экспорт пошлиналарын үзгәртүгә дә ризалашты. Ил бюджеты керемнәренең нигезен билгеләүче нефть һәм газга экспорт пошлиналарын киметү яки бетерүнең нәрсәгә китерәсен әлегә бик кузгатырга теләмиләр.

> *Ил бюджеты керемнәренең нигезен билгеләүче нефть һәм газга экспорт пошлиналарын киметү яки бетерүнең нәрсәгә китерәсен әлегә бик кузгатырга теләмиләр*

Дөрес, Россия Бөтендөнья сәүдә оешмасына кушылу белән үк барысы да бик тиз үзгәрәчәк дигән сүз түгел әле бу. Ил икътисадының кайбер секторларын яңа шартларга әзерләү өчен билгеле бер вакытка күчеш чоры каралды. Пошлиналарны киметүгә 2-3 ел вакыт бирелсә, кайбер секторлар өчен ул 7 елга кадәр сузылырга мөмкин.

Үз продукциясен чит илгә чыгаруда гына түгел, үзебезнең сату базарындагы позицияләрен саклап калу өчен җитештерүчеләребезгә катгый көрәш алып барырга туры киләчәге көн кебек ачык. Бу төрле тармакларга кагыла. Без сораштырган экспертлар, конкуренциянең көчәюе файдага гына булачак, дигән фикер үткәрде.

ТР Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Марат Галиев:

– Бөтендөнья сәүдә оешмасына керү күпләрне бербәрсенә карап тигезләшергә, квалификация күтәрергә этәрергә тиеш. Ясалма рәвештә тудырылган теплица шартлары җитештерүчеләрнең артык иркенәюенә, гомуми конкурентлыкка сәләтнең төшүенә китерде. Мөмкин кадәр ачык икътисад һәрвакыт яхшырак эшләргә мәҗбүр итәчәк.

ТР Сәүдә-сәнәгать палатасының идарә рәисе Шамил Агеев:

– Эре җитештерүчеләргә килгәндә, алар болай да инде соңгы елларда, формаль булмаса да, ВТО шартларында эшли иде. Алга таба да шулай дәвам итәчәк. Тик бер нәрсәне аңларга кирәк: безне берәү дә үз базарына болай гына чыгармаячак. Хәзер ничек кыссалар, алга таба да шулай кысачаклар. Моның өчен сәясәтне, конкурентлыкка сәләтне үзгәртеп корырга кирәк. Иң мөһим шарт – конкурентлы җитештерү булу. Бәлки ресурслар нәтиҗәлерәк файдаланылыр, ул хезмәт җитештерүчәнлеген, сыйфатны үстерүгә китерер. Мисалга Казахстан, Россия һәм Беларусь таможня берлеген генә алыйк. Бүген Казахстанда бизнес алып бару өчен шартлар Россиягә караганда яхшырак. Ә Беларусьта җитештерүчеләргә ярдәм чаралары безнең илгә караганда тагын да төгәлрәк, ачык итеп оештырылган. Безгә дә үзгәрергә кирәк: хезмәт җитештерүчәнлеген, көндәшлеккә сәләтне күтәреп, яхшы кадрлар әзерләү аша.

ТР Премьер-министры урынбасары – сәүдә һәм сәнәгать министры Равил Зарипов:

– Тармакларны яңа шартларга әзерләү өчен күчеш чоры 5-6 елга сузылачак. Бу – безнең әле ныклап эшләргә вакыт бар дигән сүз. «Сакчыл җитештерү» кебек заман технологияләрен, сыйфат белән бәйле инструментларны кулланып, республика җитештерүчеләрен сыйфатлы товар җитештерүгә кызыксындырырга кирәк.

...каршыларсың картлыгыңны?

Быел ил күләмендә хезмәт пенсияләрен ике тапкыр индексацияләргә җыеналар. 1 февральдән аның күләме 6,6 процентка артырга тиеш. Ә 1 апрельдән хезмәт пенсияләренә өстәмәнең күләме Пенсия фонды керемнәренең үсешенә бәйле булачак.

Бердәм акчалата түләүләргә дә апрель башында индексация үткәрү планлаштырыла. Моннан тыш, лаеклы ялда булып та, эшләүләрен дәвам итүче гражданнарның пенсияләрен август аенда яңадан исәпләү каралган.

Пенсионерларның шактые, лаеклы ялга чыккач та, иш янына куш булырлык керем алу өчен, эшләргә мәҗбүр. Шушы көннәрдә генә РФ Пенсия фондының ТР бүлегенең ел йомгакларына багышланган коллегиясендә Татарстан профсоюзлары федерациясе рәисе Татьяна Водопьянова китергән мәгълүматлар бер дә күңелле түгел иде. Пенсионерларның яшәү дәрәҗәсе түбән булуга, аларның сатып алу сәләте дә эшләгән вакыттагыга караганда ике тапкырга түбәнрәк булуына басым ясады профсоюзлар лидеры. Барыбызга да билгеле: кеше лаеклы ялга чыккач, аның пенсия күләме ул моңа кадәр алган хезмәт хакыннан 3-4 тапкырга кимрәк була. Кызганыч, безнең шартларда гадәти гражданнарның күбесе картлык көннәрендә үзен лаеклы пенсия белән тәэмин итәрлек хезмәт хакы алып эшләми. Пенсионерларның яшәү минимумына килсәк, бүген Татарстанда аның күләме нибары 4302 сум тәшкил итә. Бу – Идел буе федераль округында иң түбән күрсәткеч. Пермь крае, Самара һәм Түбән Новгород өлкәсе пенсионерларының яшәү минимумы, мәсәлән, безнекеләргә караганда 30 процентка югарырак. Татарстан профсоюзлары лидеры Татьяна Водопьянова моның сәбәбен республикада пенсионерларның куллану кәрзиненең (азык-төлеккә, туклану белән бәйле булмаган продукциягә һәм хезмәтләргә) сизелерлек түбән булуы белән бәйләп аңлата. Шуны күздә тотып, аз тәэмин ителгән гражданнарны социаль яклауны көчәйтү өчен, профсоюзлар әлеге мәсьәлә буенча эшче төркем төзеп, быелның беренче яртысында куллану кәрзиненә кагылышлы яңа канун эшләү тәкъдиме белән Татарстан Хөкүмәтенә мөрәҗәгать иткән.

Гамәлдәге пенсионерларның гына түгел, булачак пенсионерларның да киләчәге томанлы. Пенсияләрнең күләме хезмәт хакы күләменә турыдан-туры бәйле булганга, гражданнарны лаеклы пенсия белән тәэмин итү хезмәткә түләү системасын үзгәртүдән башка мөмкин булмаячак, дип чаң суга белгечләр. Хезмәт хаклары күләме артмаганда, бүген эшләүче россиялеләрнең 30 процентына, лаеклы ялга чыккач, пенсионерларның яшәү минимумыннан да түбәнрәк пенсия алу куркынычы яный. «Пенсия хезмәт хакына турыдан-туры бәйле булганга, бу тенденция алга таба да дәвам итәчәк», – дип кисәтә РФ Пенсия фондының ТР бүлеге идарәчесе Марсель Имамов.

Тиешле яшәү шартларын тәэмин итәрлек пенсия алу, лаеклы ялга чыккач, сатып алу сәләте пенсионерларның яшәү минимумыннан 2-2,2 тапкырга артык булсын өчен, Пенсия фондына һәр граждан өчен 38 ел дәвамында аена 6 мең ярым сумнан да ким булмаган иминият взносы кертелеп барылырга тиеш икән. Кызганыч, бүген мондый пенсия алу бәхетенә аена 29500 сумнан артыграк хезмәт хакы алып эшләүче россиялеләр генә өмет итә ала. Хезмәткәрләренә түбән хезмәт хакы түләү өстенә, иминият кертемнәрен вакытында һәм тулы күләмдә күчермәүче предприятие һәм оешмаларның саны шактый бүген республикада. Алар булачак пенсионерларның хәлен икеләтә авырайта. Татарстан предприятиеләренең яртысыннан артыгы хезмәткәрләре өчен иминият взносларын вакытында һәм тулысынча түләми икән. Пенсия фондының ТР бүлеге тарафыннан чаралар күрелү нәтиҗәсендә узган ел эш бирүчеләрнең иминият кертемнәре буенча 2 млрд сумнан артык бурычлары фондка кайтарылган. Шуңа да карамастан, бүген әле республика предприятиеләренең Пенсия фонды алдында иминият взнослары буенча 1 млрд 329 млн сумлык бурычы кала. Аның 90 проценты 59 предприятие өлешенә туры килә. Иминият взнослары буенча җыелган барлык бурычның 55 процентка якыны – «Ак Барс» холдинг компаниясе»неке. «Татарстан» авиакомпаниясенең бурычы 9 млн сумга якын. «ВАМИН Татарстан» ААҖ һәм аның бүлендек предприятиеләре, «Точмаш», «Зәй тимер-бетон эшләнмәләр заводы» да «кара» исемлектә. Сәнәгать предприятиеләрендә генә түгел, бюджет оешмаларында да иминият кертемнәре буенча бурычлар җыелу борчу тудыра.

Лаеклы пенсия булдыру өчен бүген иң мөһим шартлар дип эш бирүче белән хезмәткәр арасында легаль хезмәт мөнәсәбәтләрен булдыру, нормаль эш стажын туплау һәм хезмәт хакларын күтәрү санала. Моннан тыш, хәзер гражданнарга булачак пенсияләрне арттыру мөмкинлеге бирә торган программалар тәкъдим ителә. Бүгенге көндә россиялеләр, мәсәлән, пенсия белән өстәмә дәүләт тәэмин итүенә кагылышлы программада катнашу мөмкинлегенә ия. Аны өч ел гамәлгә ашыруның Татарстандагы нәтиҗәләре әлегә бик тыйнак. Программада халыкның 9 проценты – 335 мең генә кеше катнашкан. «Программада катнашу вакыты чикләнгән. 2013 елның 1 октябренә кадәр аңа кереп беренче түләүләрен башкаручылар гына 10 ел дәвамында дәүләтнең финанслауда катнашуына өметләнә ала», – дип искәртә Марсель Имамов.

Илдә пенсия системасын реформалаштыру дәвам итә. Бүген беребез дә, пенсиягә чыккач, реформалардан нинди отыш алачагын анык күзаллый алмый. Шул ук вакытта берәү дә, пенсиягә кадәр ерак, аңа кадәр әллә ниләр үзгәреп бетәр әле, дип, кул селтәргә тиеш түгел. Бүген дәүләткә генә карап утыра торган заман түгеллеген һәркем аңларга тиешле. Һәркемнән фонд базарындагы кебек җитез уенчы булу, пенсияләргә кагылышлы программаларда әйбәт ориентлашу, рисклардан хәбәрдар булу таләп ителә. Кем әйтмешли, үз хәлебезне кайгырту үзебезнең генә кулда.

Сәхифәне
Айгөл
ФӘХРЕТДИНОВА
әзерләде

СӘНГАТЬ ӘХРАМЫ

Без башкачарак шул. Италиядәге кебек, Яңа елга кергәндә бар искемоскыны тәрәзәдән тышка ташларга күнекмәгән. Бер урыннан икенчесенә алып куя-куя әвеш-түеш йөртеп туйганнан соң да, әйберкараның чыгарып ташларга кул бармаганнары да гел булып тора. Андыйлары исә чормага ук менеп кунаклый.

«Казан чормасы»нда ни булмас...

КҮРГӘЗМӘ

Расиха ФӘИЗОВА

ТР һәм РФ Рәссамнар берлеге әгъзасы Елена Титованың 57 эштән торган «Казан чормасы» дип аталган шәхси күргәзмәсендә дә чардакта сакланып калган шул җанга якын нәрсәләр сурәтләнә. Төгәлрәк итеп әйтсәк, күпләрне еракта калган балачагына кайтара ул. Кулыңа тотып кысканга сызгыра торган уенчыклар, плюш аюлар, эче куыш пластмасс курчаклар белән уйнап, «Мальчиш-кибальчиш» фильмын карап үскән, кушу-алу кебек гамәлләрне чут төймәсенә ышанып тапшырган төрле яшьтәге совет чоры балаларын чолгап алган дөньяны, алар уйнап үскән уенчыкларны сурәтли рәссам. Миңа калса, күргәзмәгә килгән шул чор баласы, ягъни бүгенге 40-50-60 яшьлекләр аюның берәр күзе төшкән очракта да, гаеп итмәячәк. Киресенчә, сабыйларча куанып: «Аю, мине танып, бер күзен кысты», ә икесе дә булмаса: «Аюның кояшта күзе чагыла иде», – дияр иде, мөгаен. Чөнки уйный белә ул алар белән!

«Казан чормасы» рәссам тарафыннан 2011 елның ахырында һәм 2012 елда башкарылган эшләрне үз эченә ала. Проектның нигезендә заманында социалистик көнкүреш әйберләре, уенчыклар җыйган курчакчы-рәссам Александр Стуков тупланмасы экспонатлары ята (1930-80 еллар). «Иске яңа ел» яки «Чемодан» дигән эшен автор нәкъ менә аңа багышлый. Шул ук вакытта Е.Титова үз әбисенең төсе булып сакланучы «Заря» кул сәгатен һәм кечкенә акча янчыгын күрсәтүнең дә җаен тапкан. Беренчесе күргәзмәнең үзәк инстолляциясендә («Йөри торган сәгать») үткән вакыт символы буларак чылбырлы дивар сәгате белән янәшә уңышлы гына кереп киткән. Акча янчыгы исә совет чорының кызыл унлыклары, өч һәм биш тәңкәлек чын кәгазь акчалар җирлегендә сурәтләнгән.

Уйга килгән — алга килде

Елена Титова иҗатын даими күзәтеп килүчеләр абайлый булыр: рәссам, гомумән, иске әйберләргә битараф түгел. Моннан элек самавырларга багышланган күргәзмәсендә дә, майлы буяулар белән башкарылган зур-зур эшләре янәшәсендә, үзе яши торган йорттан ерак түгел генә җыела торган Борча базарыннан (Блошиный рынок) сатып алган берсеннән-берсе матуррак, берсеннән-берсе зуррак биш күмер самавыры бизәгән иде күргәзмәне.

– Чыннан да берара минем бары тик иске, борынгы әйберләр белән генә эш итәсе килгән чакларым да булды. Чөнки иске әйберләр, җылы, образлы булу өстенә, аларны сурәткә алуның үз кызыгы, тәме бар – үзең теләгән фактураны, образны эзлисең, тудырасың. Вакыт тузаны утырган, шуның өстенә кыршылган-кырылган борынгы әйберләр рәссам өчен гомумән зур табыш. Мине, мөгаен, кечкенә чакта чолгап алган әнә шул үзенчәлекле мохит – әби-бабай, алар яшәгән йорт рәссам иткәндер дә... Әби-бабам Наталья Яковлевна һәм Александр Романович яшәгән Ува бистәсе Ижевск каласыннан ике сәгатьлек юл аралыгында. Аларның тузанга баткан чормасында да ниләр генә булмый торган иде: әллә нинди ят, кечкенә уенчыклар белән бизәлгән ясалма чыршы, умартачы бабамның эш кораллары, уенчыклар, плюш аюлар... Ул миңа үзе бер кызыклы дөнья кебек тоела торган иде. Әле булса хәтеремдә, әти урамда утын кисә. Башкалар киселгән утынны ишегалдына ташыйлар. Дымлы-юеш көн. Шунда өелеп калган каен тузлары арасында чүгәләп диярлек мин утырам. Миндә беркемнең эше булмаган кебек, минем дә башкаларда гамем юк. Яңгырдан соң шактый ук йомшара төшкән каен тузын тәмләп кенә телемләп кубарам. Кубарган саен берсеннән-берсе затлырак яңа рәсемнәр килеп чыга. Кайсысы урман, кайсысы елга... Рәссам булып китүем, мөгаен, кечкенә чактан күңелгә уелып калган шул мизгелләр белән бәйледер дә... – ди Елена Александровна, булачак рәссамның сизгер күңелен «уятып җибәргән» хатирәләре белән уртаклашып.

Рәссамның бүгенге уңышлары, сүз дә юк, бер селтәнүдә тумаган. Олы сәнгатькә илтүче һәр адымы берәм-берәм җепкә тезгән энҗе-мәрҗәнгә тиң. Һәр адым – үсеш чорының бер энҗесе. 8 яшьтә йөри башлап, 9 ел буе Ижевск каласының 9 нчы сәнгать мәктәбендә шөгыльләнү дә «Киләчәктә нинди һөнәр сайларга?» дигән икеле-микеле сорауны кабат бирмәслек итә. Нәселдә рәссамнар юк югын. Тик әнә бит әтисенең әтисе Александр Константинович фронтта картограф булып хезмәт иткән. Үзенә кечкенә генә этюдник эшләтеп, сугыш чорында да Венециянең матур күренешләрен, төрле натюрмортлар ясый торган булган. Бу инде аз түгел. 1996 елда Удмурт дәүләт университетының сынлы сәнгать-графика бүлегендә укып чыккан кыз озакламый Россия Сәнгать академиясенең Казанда Харис Якупов җитәкчелегендәге остаханәсен тәмамлый (2001 ел). Шул ук елны ТР һәм РФ Рәссамнар берлегенә кабул ителә. 6 еллап КХТИдагы җиңел сәнәгать институтының дизайн кафедрасында доцент булганнан соң, 8 ел дәвамында ирекле рәссам буларак иҗат итә. Бу еллар, иреккә чыгып, канатларны ныгыту гына түгел, очар кыйбласын билгеләү, иҗат колачының мөмкинлекләрен барлау да булгандыр рәссам өчен. Елена Александровна соңгы ике елда «Эбиволь» галереясының баш рәссамы. Янәдән талпынып югарыга күтәрелеп китәр өчен бер зур иҗат мәйданы булыр күк анысы да. Чөнки бүген инде Елена Титованың үз мәктәбе, үз шәкертләре бар. «Эбиволь» ЯАҖ директоры, ТР иҗтимагый палатасы рәисенең урынбасары – ТР сәүдә-сәнәгать палатасының идарә рәисе урынбасары Татьяна Вениаминовна Забегина ярдәмефатихасы белән бер ел элек эшләп китте ул. Былтыр сентябрь аенда «Эбиволь» күргәзмә залында «Ышанам. Өметләнәм. Яратам» дигән ретроспектив күргәзмә нәкъ әнә шул максатны күздә тотып, ягъни күргәзмәгә килүчеләр рәссам белән якыннан танышсын, иҗатын күреп үзләрендә дә рәсем ясыйсы килү теләге уянсын, дип оештырылган иде.

* * *

Рәссамның ТР сынлы сәнгать музеенда 10 мартка кадәр эшләячәк «Казан чормасы»ның тамашачыда резонанс тудыруы бәхәссез. Юкка гына: «Еламыйча чак-чак тыелып калдым», – дими инде күргәзмәдән чыгучы өлкән буын вәкилләре. Беренче карашка инде хаҗәте юклыктан чормага ташланган әйберләр дә хәтерне уятып, сискәндереп җибәрергә сәләтле икән шул. Тегe яки бу әйбернең чүплеккә ташланмый калынуы үзе бер могҗиза бит. Димәк, хикмәте бар, нидер тота. Еракта калган кабатланмас балачак үзе тарта, күрәсең, чабудан.

Күңел күзең күрсә генә...

БУЛМАС ДИМӘ

Тумыштан сукыр, ягъни бу якты дөньяны гомерендә бер генә тапкыр да күргән кеше түгел ул. Иллә мәгәр 60 яшьлек Эсреф Армаган үзен белгәннән бирле рәсем ясый.

Төгәлрәк булсак, 6 яшендә кулына карандаш алган малай 18дә инде майлы буяуларга күчә, 40ның өске ягына чыккач, тиз кибә торган гуашьның мөмкинлекләрен сыный. Майлы буяуларны киндергә кылкаләм белән түгел, ә бармаклары ярдәмендә сала ул. Бер салган буявы кипкәч кенә икенчесенә керешә. Эшләре үзе туып үскән Истанбулда гына түгел, Италиядә, Кытайда, Голландиядә һәм Чехиядә дә күргәзмәләрдә күрсәтелгән. Аның перспектива һәм күләгә төшү таләпләрен саклавына, төсләрне шуның кадәр дә тоя алуына шаккаталар. Ә моны ул үзе бик гади генә аңлата: диңгез – зәңгәр, агачлар яшел булырга тиеш... Гадәти булмаган рәссамның баш миен тикшерү шуны күрсәткән: рәсем ясаган вакытта аның баш миенең күрү өчен җавап бирә торган өлеше күрә торган кешенеке кебек үк эшли башлый. Фәнни тестлар да аңарда «эчке күрү» барлыгын ачыклаган.

КҮРМИ КАЛМА

Юбилей күргәзмәсе дәвам итә

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында ТРның халык рәссамы, Бакый Урманче премиясе лауреаты Софья Кузьминыхның 85 яшьлек юбилее уңаеннан ачылган кулланма-гамәли сәнгать күргәзмәсе эшен дәвам итә. 1978 елдан бирле шәхси күргәзмәләрен үткәреп килүче рәссамның иҗаты Татарстаннан читтә дә танылу ала. «Зур Идел» төбәк күргәзмәләрендә (1969-1998), Санкт-Петербургта кулланма-гамәли сәнгать күргәзмәсендә (1990) эшләре куела. 2002 елда ул Дижонда (Франция) узган Бөтендөнья

күргәзмә-ярминкәсендә катнаша.

Күргәзмәдә авторның 50ләп һәм шул ук вакытта кызы – рәссам Светлана Гарбузова белән берлектә иҗат иткән берничә эше күрсәтелә. Күн мозаикасы, күнгә бизәк басу, күнгә чигү һәм тукымага бизәк төшерү кебек техникаларны кулланып, Софья Кузьминых традицион татар костюмына хас булмаган билбаулар, перчатка, сумка һәм акча янчыклары һ.б. иҗат итә.

Экспозиция киңәйтелде

А.А.Шишкинның Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы Графика залының яңартылган экспозициясен карарга чакыра. Музей-йортның Графика залындагы экспозиция бөек останың туган көне уңаеннан киңәйтелде. Музейга килүчеләргә тәкъдим ителгән 22 график эш арасында рәссамның XIX гасырның 70-80 нче елларында башкарып, моңа кадәр бер тапкыр да күргәзмәләргә куелмаган гаҗәеп офортларын да күрергә мөмкин булачак.

Сәхифәне Расиха ФӘИЗОВА әзерләде

ЯШЬЛӘР СУЛЫШЫ

Аны: «Менә килә, менә килә», – дип, дүрт күз белән көтәбез. Ә ул, безне котырткан сыман, тиз генә уза да китә. Укучылар һәм студентлар тәмле кәнфит кебек яраткан каникулларны әйтүем инде! Сессияне ябып, каникулга чыксаң да, ял итмәгән сыман буласың. Энә белән кое казучылар тәмле әйбер күп булмаганын һаман аңларга теләмиләр, ахрысы. Күпме ял итсәң дә, җитми безгә. Миңа әни дә: «Күпме ял итсәгез дә, аз тоела инде», – ди. Хәер, чыннан да шулай түгелме соң? Укыганда гына алны-ялны белмичә тырышабыз. Бер көн ял бирделәрме, бетте инде. Ялкаулык дигән абзый ишек шакый башлый. «Уку качмас, ял итеп калырга ашык!» – дип, мәкерле хәйләсен кора ул. Тик ялкауланырга ярамый. Әнә, Универсиада булу сәбәпле, бу семестр кыскарды. Уку Татарстанның барлык вузларында 15 майда тәгәлләнәчәк. Быел имтиханнарны шомырт чәчәк атканда тәгәлләрбез, Алла боерса. Алайса, без җәйге сессияне тапшырганда, Сабан туйлары узып, чиллә җитә иде... Ярар, хыялланып эш чыкмас. Тырышып-тырмашып укырга кирәк. Ә кышкы каникул хатирәләрен яңарту начарга илтмәс. Шуңа бүгенге сәхифәне нәкъ каникулларга багышлыйбыз. Егетләр-кызлар, сөйләп җибәрегез: ялларны кем ничек үткәрде?

«Кем, кем, ә мин — Кыш бабай!»

Кышкы каникулларны ничек инде Кыш бабайсыз күз алдына китереп була? Бу һич мөмкин түгел. Студентлар әлеге тылсымчының барлыгына бик үк ышанып бетмәсәләр дә, Кыш бабай роленә рәхәтләнеп кереп, балалар һәм олыларның күңелен ачып йөриләр. Узган ел Казан театр училищесын тәмамлаган Илназ Хәйбуллин да быел да «ялгыш кына» Кыш бабай булган.

ШӨГЫЛЬ

«Моңа кадәр Кыш бабай булып эшләгәнем булмады, – ди яшь Кыш бабай. – Быел да исәп юк иде. Мин бары тик әлеге «Кыш бабай һәм Кар кызы» проектының продюсеры. Шуңа телефон аша клиентларга хәбәрләр җиткерермен, дип уйлаган идек. Тик без уйлаганча килеп чыкмады. Кыш бабай булып минем белән бергә укыган егетләр йөрисе иде. Ахырдан, заказлар күп булу сәбәпле, үземә дә Кыш бабай булырга туры килде».

Шулай итеп, Илназ, көтмәгәндә-уйламаганда, кызыл костюм киеп, үзе дә театр артистларының балаларын, музыка мәктәпләрендә укучыларны котлап йөргән.

Бәйрәм программалары төрлечә булган. Театраль белем алгач, егетләр сынатмый. Үзләре катнашкан спектакльдән пингвин ролен башкаручы актерны да иярткәннәр. Шуңа да театральләштерелгән тамашадан ким булмаган.

Балалар бакчасы һәм мәктәпләрдә Кыш бабайның бушка бүләкләр алып килмәгәнен беләбез. Кыш бабай белән Кар кызының эше программаның нинди булуына карап бәяләнгән. Икесенең хезмәт хаклары 1000-3500гә кадәр булган.

«Кемне күбрәк котларга туры килә иде: олыларнымы, балаларнымы?» – дигән сорауга Илназ болай дип җавап бирде: «Балалар янына дип чакырталар. Ләкин олылар, Кыш бабайны күрү белән, үзгәреп китә, яшь чакларын искә төшерәләр. Ялгышмасам, олылар янына, Кыш бабай булып, күбрәк тә барырга туры килде бугай».

Яңа ел җиткәндә, Кыш бабай һәм Кар кызы белән кызыклы хәлләр дә булмый калмый. Мәсәлән, И. Хәйбуллинга әзерлек эшләрен өенә дә алып кайтырга туры килә. Ә өйдә 6 яшьлек сеңлесе булачак Кыш бабайның телефоннан сөйләшүләрен дәшмичә тынмый тыңлап утырган. Аннары әнисе янына барып: «Абый Кыш бабайның булышчысы булып эшлиме әллә?» – дип сораган. Уңай җавап ишеткәч, Кыш бабайга үзенең хатын тапшыруын үтенгән. Үз сеңлесе янына да Кыш бабай булып барган егет! Аннан соң сеңлесе: «Кыш бабайның тавышы синекенә охшаган иде. Әллә булышчысы булгангамы?» – дип тә сорап куйган.

Алинә МИННЕВӘЛИЕВА

«Канатлы сүзләр»

♦ *Каникулларда гомер тизрәк үткән сыман тоела.*

♦ *Әгәр иртәнге сәгать 7дә «Вконтакте» сайтында дусларың он-лайнда түгел икән, димәк, каникул җиткән дигән сүз.*

♦ *Каникулга планнарым шулхәтле күп иде. Нәтиҗәдә һәрвакыттагыча килеп чыкты: компьютер – йокы – компьютер – йокы – компьютер – йокы. Системага каршы килеп булмый.*

Ә СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?

√ Каникулларны яратмаучы укучы юктыр ул, тик бу сүзнең килеп чыгышын бөтенесе дә белми. Латин теленнән тәрҗемә итсәк, «эт», «көчек» килеп чыга. Каникула дип борынгы римлылар Зур Эт (Большой Пес) йолдызлыгындагы иң якты йолдызны атаганнар. 22 июльдән 23 августка кадәр кояш шушы йолдызлыкта торган. Нәкъ менә шул вакытта дәресләрдә тәнәфес булган – каникуллар җиткән. Әкренләп «каникуллар» укудагы җәйге һәм башка ел фасылындагы тәнәфесне аңлата башлаган. Америка, Англия, Франция һ.б. илләрдә парламент эшендәге тәнәфесләрне дә каникул дип атыйлар.

√ Чехиядә мәктәп каникуллары кыш һәм җәй көне була. Җәйге каникуллар 2 ай. Кытайда кышкы каникуллар декабрь ахырыннан алып февраль башына кадәр. Бу вакытта ил Яңа елны бәйрәм итә. Австралиядә җәйге каникуллар Раштуага берничә атна калгач башлана.

√ XIX гасырда АКШта балаларның хәзерге кебек җәйге каникуллары булмаган. Авыл балалары уңыш җыюда әти-әниләренә булышырга кайтып киткән. Ә шәһәрнекеләргә һәр өч ай саен бер атна ял бирелгән. XIX гасыр ахырында мәгариф системасында, бөтен укучыларга бертөрле озынлыктагы каникул булсын өчен, яңа реформа тәкъдим ителә. Бу карар арыганлыкны киметер өчен дә чыгарыла.

СОРАШТЫРУ


Фото бизәү өчен бирелә

Гүзәл Шәяхмәтова, КИТТУ-КАИ:

– Каникулларны, гадәттәгечә, ял итеп түгел, эшләп уздырдым. 30, 31 декабрь һәм 1 гыйнвар көннәрендә дә таксида оператор булып эшләдем. Иң кызыгы, мөгаен, Яңа ел төнендә булгандыр. Хәтта такси чакыртырга шалтыратканда танышучылар да булды. Тик без бит эш урынында, монда ярамый. Андый егетләрне бәйрәм белән котладык һәм саубуллаштык. Сәгать 12не сукканда барыбыз да берничә минутка җыелдык. Аннары тагын эшкә утырдык. 12гә кадәр машина чакыртучылар күп булмады, ә аннан соң телефон бер дә тынып тормады.

Алмаз Давытов, укучы:

– Быелгы каникулны актив рәвештә уздырдым. Аягымнан чаңгы һәм тимераяк төшмәде диярлек. Көн саен дусларым белән чаңгы шудым. Безнең авылдагы нарат урманында ике яклы тау бар. Тауның бер ягыннан төшсәң, каршы яктагы икенчесенә менеп китәсең. Шунда мәш килдек. Бер дустымның чаңгыга күптән басканы юк иде. Ул да куркуын җинде. Ә хәзер укуның беренче көнендә үк компьютер артында утыргач, буыннар каткан сыман тоела. Шуңа чаңгыны уку вакытында да ташламыйм әле!

Энҗе Шакирова, КДМУ:

– Ялларны гадәти булмаганча үткәрәсе идем. Тик авырырга туры килде. Шуңа өйдә яттым. Күп кеше чирләде бугай каникулда. Сакланырга кирәк шул. Саклангынны саклармын, дигән бит Ходай.

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

Аяк терәп бүләк сорый

Бу Яңа ел бәйрәмнәре дә бакча-мәктәп балаларын боза гына, ахрысы. Берсеннән-берсе уздырып киреләнергә генә куш! Тегесе ошамый да, монысы җитми аларга.

Энемне Яңа ел спектакленә алып барган идем. Балалар тамашадан соң әкият геройлары, Кыш бабай һәм Кар кызы белән бергә фойеда уйнады. Шигырь сөйләгән яшь тамашачыга геройлар бүләкләр тапшырды. Бәйрәм бетеп, гардеробка төштек. Киенә генә башлаган идек, бер кыз әбисенә киреләнепме-киреләнә! «Бөтен кешегә Кыш бабай бүләк бирде. Ә миңа юк», – ди теге кызый. Әбисе ничек тынычландырырга белми үзен. Алай итә, болай итә. Ахыр чиктә: «Мин бүләк биргәнне күрмәдем, сиңа гына карап тордым», – дип, чираттагы ялганын уйлап тапты. Марина (әбинең оныкчыгының исеме шундый) үзе киенә, үзе еларга маташа: «Ә мин барысын да күреп тордым бит», – ди.

Әбисе, яратып, тукта, чү, бәйрәм булсын, дип алып килгәндер инде. Рәхмәт әйтәсе урынга ниләр кылана! Без кечкенә вакытта Казанга бару үзе бер бәйрәм иде. Башкалага барып, концерт-театрга да керсәң, монысы – икеләтә бәйрәм. Хәзерге кечкенә балаларга карыйм да шаккатам! Үзләре кечкенә, ә таләпләре олыларныкыннан да югарырак. Әллә миңа гына шулай тоеламы?

Таңсылу КАМАЛОВА

Сәхифәне **Алинә МИННЕВӘЛИЕВА** әзерләде

СӘЛАМӘТЛЕК

Даруны үзебез сайлыйбыз?!

Якын киләчәктә дару препаратлары өлкәсендә безне яңалык көтә. Россия табиблары рецепт язганда дару препаратларының сатудагы исемен түгел, ә дәвалый торган матдәнең атамасын гына язарга тиеш булачаклар.

ЯҢАЛЫК

Чулпан НӘҖИПОВА

Мәсәлән, табиб авыруга составында парацетамол булган дару алырга кушса, авыру иң арзанлы аналогны, ягъни «Парацетамол»ның үзен, әллә инде составында әлеге матдә булган башка кыйммәтлерәк препаратны аламы – монысын үзе хәл итә. Хәзергә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы Юстиция министрлыгында теркәлү уза, закон исә 1 июльдән гамәлгә керергә тиеш дип көтелә. Әлеге үзгәреш нәрсәгә кирәк дигәндә, аның ярдәмендә кайбер табибларның һәм фармацевтика компанияләренең үзара килешеп эшләүләренә чик куймакчы булалар. Икенчедән, авыруларга даруларны үз мөмкинлекләреннән чыгып алырга юл калдыралар. Әмма шул ук вакытта яңа кагыйдә табибка, авыру ниндидер даруны кабул итә алмаган очракта, аңа аерым бер препаратларны билгеләүне дә тыймый, диелә «Российская газета»да.

Билгеле булганча, бүген даруханәләргә барсаң, даруларның күплегеннән башлар әйләнә. Даруны табиб язып бирә икән, бу очракта инде нәкъ менә шул язган препаратны алырга кирәклеге турында бер шик тә калмый иде: аның нинди бәядә булуы да әллә ни мөһим түгел кебек – кирәк икән кирәк инде. Авырыйсы килми бит. Гәрчә шундый ук күпкә арзанлырак препарат һәм аның составы да шул ук булса да. Бу закон үз көченә кергәч, алырга кирәкле даруларның вариантларын даруханә хезмәткәре тәкъдим итәргә тиеш булачак, чөнки бүгенге көндә составлары бер үк булса да, төрле брендлар астында, төрле аналогларны чыгара торган бик күп фармацевтик компанияләр бар. Бертөрле үк тәэсир итә торган даруларның бәяләре дә бер-берсеннән бик күпкә аерылып тора.

Хәл ителмәгән мәсьәләләр дә юк түгел. Кайбер дарулар составы ягыннан бик катлаулы булып, аның барысын да рецепт бланкына язып бетерү дә мөмкин түгел, ди белгечләр. Икенчедән, даруның нинди дозадагысын алырга кирәклеген дә табиб кына хәл итә ала бит.

Табибларның да фикере әлеге үзгәрешкә карата бертөрле генә түгел. Берәүләр, кайбер кыйммәтлерәк дарулар очсызлы аналогларына караганда күпкә яхшырак һәм тизрәк тәэсир итә – шуны да исәпкә алырга кирәк. Арзанлысына өстенлек биреп, хаталанырга да мөмкин, дисәләр, икенчеләр, рецептта даруның исемен язмаган очракта да, табиб үзенең киңәшләрен, нинди дару алырга кирәклеген телдән дә әйтә ала, шуңа күрә әллә ни борчылырга һәм бу яңалыктан куркырга кирәкми, дип уйлый.

БЕЛЕП ТОР!

Гыйнвар аенда инде узган елның җәендә үк кабул ителгән «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» дип аталган закон үз көченә керде. Яңа закон буенча, хәзер кан тапшырган өчен акча түләмәячәкләр, донорны бары тик кан тапшырган көнне бушка ашатачаклар гына.

Фотолар бизәү өчен бирелә

КАН ТАПШЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ ЯҢА ТӘРТИПЛӘР

Дөрес, закон граждан алдында сайлау хокукын да калдыра: канны акчага тапшырамы ул яки бушкамы – үзе хәл итә, диелә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында. Кан тапшырган өчен түләү исә, Сәламәтлек министрлыгы билгеләгәнчә, кайбер очракларда гына, аерым алганда сирәк очрый торган төркемдәге канны тапшырганда, тромбоцитоферез һәм плазмафереза үткәргәндә башкарыла. Аның каравы Россиянең мактаулы донорларына ел саен түләнә торган акчаның күләме 1,5 тапкырга арткан. Хәзер ул 9959 сумга тигез.

Кан тапшырган өчен акча түләнми башлагач, белгечләр, кан тапшыручылар бермә-бер кимеячәк, дип уйлый, чөнки кан донорларының чиреге акча өчен килә. Болар барысы да кан запасын киметәчәк, дигән фикерләр бар.

Кемгә ярый, кемгә юк?

Бүгенге көндә, статистика буенча, һәр өченче кешегә гомерендә бер тапкыр кан салу кирәк була. Әгәр сезгә 18 яшь һәм сез сау-сәламәт икән, гәүдә авырлыгыгыз 50 килограммнан да ким булмаса, сез кан тапшыра аласыз. Ир-атларга канны елга 5 тапкырдан да күбрәк, хатын-кызларга исә 4 тапкырдан да күбрәк бирергә ярамый. Кан тапшыру процедурасы арасында 60 көннән азрак вакыт узарга тиеш.

Кан тапшыручы ул – беренче чиратта сәламәт кеше. Кан тапшырырга ярамаган билгеле бер авырулар да бар. Алар иң элек СПИД, ВИЧ, гепатит, туберкулез, кан һәм онкология авырулары, наркомания, алкоголизм һ.б. Шулай ук ишетмәү, телсезлек, психик авырулар, гипертония, йөрәк авырулары һ.б. булганда да кан тапшырырга ярамый. Күптән түгел генә салкын тидереп, грипп яки ангина белән авырып алган булсагыз, яисә яңарак кына тешегезне алдыргансыз икән, татуировка яки пирсинг ясатсагыз, шулай ук прививка ясаткан булсагыз, канны вакытлыча тапшырырга рөхсәт ителми.

Кан тапшыру организмга бернинди дә тискәре йогынты ясамый, ди белгечләр. Кеше сәламәт икән, ул бик тиз тернәкләнә. Кан тапшыргач та була торган билгеләр: баш әйләнү, хәлсезлек, кан басымы төшү һ.б. берникадәр вакыттан соң юкка чыга.

Даими рәвештә кан тапшыру сәламәтлек өчен дә файдалы. Бердән, донорлар тизрәк савыга, икенчедән, аларның каны тизрәк яңара, кандагы карт күзәнәкләр дә тизрәк чыгарыла. Һәм донорлар кан тапшырмаучыларга караганда уртача алганда 5 елга озаграк яши, ди белгечләр.

СЕЗОН АВЫРУЫ

Грипп йоктырмауның иң гади ысулы бар

Грипптан саклануның иң яхшы һәм гади ысулы белән Америка белгечләре бүлешә. Авырмас өчен, даими рәвештә кулларны яхшылап юып тору кирәклеген барыбыз да белә, бигрәк тә урамнан кергәннән соң. Әмма грипптан саклану өчен тагын бер мөһим булган кагыйдә бар: биткә дә кагылмаска кирәк. Америка галимнәре, гел биткә тиеп торганда, кулларыгызны юып тору гына сезне грипптан саклап кала алмаячак, ди. Бу кагыйдәне икесен бергә үтәгәндә генә грипптан сакланып була.

Теш сызласа, нишләргә?

БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ

Теш сызласа, әлбәттә, тизрәк теш табибына барырга кирәк, чөнки өзлегүләр барлыкка килүе бар. Әмма тиз арада гына табибка барырга мөмкинлегегез юк икән, берничә киңәшне истә тотыгыз:

1. Авыз эчен кайнар төнәтмә белән чайкагыз. Моның өчен ромашка, шалфей, календула (тырнак гөле) яхшы. Эштә булган очракта тешне яшел чәй белән дә чайкарга була. Дөрес, җылы төнәтмәне дә кулланырга ярый, әмма бу вакытта аның нәтиҗәсе генә булмаска мөмкин.
2. Авыртуны баса торган дару эчегез.
3. Сызлый торган тешне, ашамлык валчыкларыннан чистартып, канәфер маенда (даруханәдән алырга була) чылатылган тампон белән эшкәртү яхшы, чөнки ул авыртуны басу үзлегенә ия.
4. Авырткан урынга тышкы яктан кайнар әйбер куеп торырга һич кенә дә ярамый!

ХӘБӘРЛӘР

Авыруларга — беләзекләр

Республика медицинасында яңалык: хәзер хастаханәгә ятарга килгән пациентның кулына махсус беләзек кидертәләр. Аңа исә термопринтер ярдәмендә авыруның исем-фамилиясе, медицина кенәгәсенең номеры языла. Беләзек суга да, медицинада кулланыла торган төрле юу чараларына, сыеклыкларга карата да чыдам. Дөрес, әлегә авыруларны бу ысул белән танып белү Чаллы шәһәренең ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә генә кулланыла. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында билгеләнгәнчә, бу республикада пилот программа булып тора. Аның максаты – сәламәтлек саклау өлкәсендә очрый торган хаталарны киметү һәм авыруларның куркынычсызлыгын тәэмин итүне күтәрү. Авыруларга беләзекләр кидерү аларны теркәүне дә тизләтергә мөмкинлек бирә.

Стресстан менә нәрсә коткара

Апельсин, мандарин, хөрмә, кишер, яфраклы салатлар – стресстан котылу, һәрвакыт оптимист булып калу өчен әллә ниләр кирәкми дә икән бит. Әлеге яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең кәефне күтәрү сәләтенә ия булуларын Гарвард университеты галимнәре ачыклаган. Моның өчен алар мең кешедән сораштыру үткәргәннәр һәм кан анализын алып караганнар. Әлеге продуктларны күбрәк ашасагыз, бернинди стресс та сезне җиңә алмас, ди галимнәр.

Сәхифәне **Чулпан НӘҖИПОВА** әзерләде

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ШӘХЕС

Айдар Хәлимнең бу роман-эпопеясен укып чыкканга байтак вакыт үтсә дә, андагы фикерләр, язмышлар, вакыйгалар күңелдән китмиләр, җанны әрнетәләр, тирә-якның, кешеләрнең, җәмгыятебезнең яшәеше, үткәне, киләчәге ныграк уйландыра.

«АЙДАР АГАдан соң гына...»

Зиннур ЗАКИРОВ,
Татарстанның атказанган табибы

Бөек язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Балта кем кулында», «Урамнар артында яшел болын», «Ягез, бер дога» повесть һәм романнарыннан соң кыргыз-татарыбыз Чыңгыз Айтматовның «Гасырларга тиң көн», «Ахырзаман», «Тавро Кассандра» китапларын укыгач, алардай югарылыктагы, алардай уйландыргыч, алардай тетрәндергеч күләмле әсәрләргә юлыкканым юк иде.

Хунвейбин романы, минемчә, ул бөек әдәби әсәр генә түгел, ә олы тарихи, фәнни, фәлсәфи әсәр дә. Шул ук вакытта ул караңгы да, шомлы да, татарыбыз үзенең ачы язмышын аңларга тырышуын, күпләренең инде аңлый да башлавын, «БЕЗ – ИСӘН» дип сөрән салып, уйлардан гамәлләргә күчә башлавын тасвирлаган, шуның белән киләчәгебезгә өмет тә уята торган олы хезмәт. Минемчә, Айдар ага аны гомере буе уйлаган, гомере буе язгандыр сыман.

Бу алты китаптан торган өч томлык зур күләмле әсәр гади роман түгел, ә гаять катлаулы. Мин аны музыкадагы Олы хор һәм Олы оркестр белән башкарылучы Олы симфония әсәре белән яки Олы эпик халык операсы белән чагыштырыр идем. Яки йөзләгән-меңләгән өлешләрне үз эченә алган, тик ерактан карап кына бөтен итеп аңлап, бәяләп булган Олы рәсем-панного тиңләргә дә буладыр. Бәлки күп дистәләгән серияләрдән торган, бөек татар артистлары, режиссерлары, музыкантлары эшләгән Олы кино аңа тиң булыр иде сыман.

Хунвейбин роман-эпопеясе тарихи вакыт буенча да гасырдан артык киңлекне ала: XIX гасыр урталары – XXI гасыр башы.

Татарстан, Россия, Кытай, Америка – алар барысы да ТАТАР ДӨНЬЯСЫ киңлекләре буларак тасвирлана. Мамадыштагы Сәләхиләрнең изге нигезләре булган Кизләү авылы, меңәр еллык бердәм татар иленә кергән тугандаш уйгыр җирләрендә нигезләнгән, тик соңыннан XX гасыр денсезләре Сталин һәм Мао килешеп Кытай ягында калган Кизләү 2 авылы. Инде ул йортлары да туздырылгач, Американың бер штатында Сәләхиләр нәселенең дәвамчысы тагын Кизләү 3не торгыза. Туктаган җирләрендә үзләренең Кизләүләрен торгызалар, шул җирләр өчен кан, яшь, тирләрен түгәләр татарлар – барган урыннарында «ростовщик» банклары ачмыйлар, җиргә сыеналар, җирне олылыйлар.

Роман колачлаган тагын олы киңлек – ул анда тасвирланган йөзләгән, меңләгән татарларның үткән һәм бүгенге язмышы, шөгыльләре, яшәү халәтләре, моң-зарлары, шатлык-бәхетләре.

Затлы Сәләхиләр нәселе, аларның дәвамчысы дөнья зыялысы Иркен ага аша татар-төрки кавеменең меңәр еллык, Монтьескелар сокланган тарихына, Атилла, Чыңгыз, Туктамыш, Олуг Мөхәммәт бабаларыбызның шанлы дәүләтләр тотканнарына инанасың. Аларның зыялылыгын, иманлылыгын, кешелеклелеген күреп, 2 нче меңьеллыкның иң Олы заты дип табылган Чыңгыз бабабызның ЯЗУ (Яса, Писание) нигезендә йөзләгән халыкларны берләштергән, үз заманы өчен алдынгы, гадел җәмгыятъ төзүенә дә һичбер шигең калмый.

> ***Айдар аганың күзе — ялангач сыркыган татарлык җаны, татарлык рухы белән тоташкан булыр. Шуңа да аның күрмәгән әйбере, җитмәгән җире, кысылмаган нәрсәсе, кермәгән тишеге юк...***

Айдар ага әсәрендә бүгенге заманыбызның гади дә, гыйбрәтле язмышлы да, иманын югалтмаган дистәләгән якты кешеләрне яратып, сокланып тасвирлаган. Китапчы Рагыйб, Зөфәретдин абзый, Магәриф кардәш, Ачулы Зөфәр, Җәкәү дәдәй, Мәгрифә апа, Мөкәррәмә түтки, Ильяз һәм Биарсланнар – һәрберсе гыйбрәтле язмышлы, фикерләре, гамәлләре белән милләтебезнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә өмет уяталар.

Узган гасырның 90 нчы елларындагы татар милли күтәрелешенең төп казаны булып Чаллы шәһәре, аның рыясыз һәм романтик милли хәрәкәте вәкилләре торды. Аларның күбесе авыллардан, бурлыкка баткан предлар, бригадирларга түзәргә теләмичә, «бөек» төзелешкә – КамАЗга килгән бунтарь егет һәм кызлар. Татарстан суверенитеты өчен көрәшнең оеткысы алар иде. Айдар ага үзенең тарихи да булган шушы китабында әлеге реаль көч булган хәрәкәтне, үзенең дә танылган көрәштәшләрен яратып тасвирлаган.

Алар янында бүгенге җәмгыятьнең олы афәте булган әтрәк-әләмлек – хунвейбинлык баткагына бата баруын да автор бөтен ачысы белән күрсәтә. Үзебезнең татар Зоммерлары, Хромосомнары, Икзимнары, Фикция Саматовналары рухи шапшаклар, милләтнең корткычлары итеп күрсәтелә.

Баксаң, заманында бөек Чыңгызыбыз керткән «манкортлык» та алай ук куркыныч булмаган сыман, чөнки ул күбрәк аерым кешеләрнең афәте.

Ә әтрәк-әләмлек (туган телебездә нинди җирәнгеч атама кушканнар андыйларга) бигрәк тә куркыныч, чөнки ул тиз йогучан, шуңа да тиз таралучан – чума, холера кебек. Хунвейбинлык җәмгыятьнең барлык катламнарына да тиз тарала, елдан-ел глобальрәк була бара. Гасырлар буе ныгыган дала чирәм җирләрен сукалап ташлап, алдагы елларда ком бураннарында харап булган уңдырышлы өске катлам кебек ул. Аяз аганың «Балта кем кулында» повестенда ул әтрәк-әләмнәр яшь урманны кырсалар, бүген алар инде йөзләгән татар мәктәпләрен, татар кафедраларын, татар гуманитар институтын ябалар, татарның изге истәлеге «Болгар» номерларын вәхшиләрчә җимерәләр – без булдырабыз, диләр. Әле ярый бу гыйбрәтләрне Аяз ага күрмәде. Шәүкәт ага Галиев, олы гөнаһ белән китәбез – Тукаебызны саклый алмадык, дип елый-елый әйтте...

Рухи әтрәк-әләмлекнең югары катламда үрчүе җанны бигрәк тә әрнетә, куркыта... Аллага тапшырдык инде...

Әсәрдә чиксез олы талант белән тасвирланганы – бүгенге татарыбызның мәдәнияте, мәдәни тарихы, халкыбыз энҗе-мәрҗәннәре – аның шагыйрьләре, шигърияте. Автор нинди олы нәзакәт белән, искиткеч урынлы итеп, Тукаебыз, Гафуриебыз, Закир һәм Сәгыйть Рәмиевләребез, Такташыбыз иҗаты аша, җәмгыятьнең фәлсәфи халәтен, җанын, рухын күрсәтә алган.

Романның мавыктыргыч та, бик моңлы да булып тууында андагы хатын-кызларның бик тә матур, татарларга гына хас сөйкемле итеп, самими күңелле итеп тасвирлануы да сәбәпче булгандыр – аларның хәдисләрдәге «оҗмах ул – аналарның аяк астында» диюгә тәңгәл килүендәдер. Илаһи җанлы Мәдинәсе, дөньяга бәхет алып килергә, бәхетле булырга яратылган Сихәт сылу, Сәгыйдә сылу, башкорт чәчәге Зөһрә сылу – аларны сагынасың, хәерле язмыш теләп каласың.

Әсәрнең тагын бер үзенчәлеге – аның телендә: ул әдәби татар телендә генә түгел, ә әдәби ТАТАР ИЛЕ телендә. Баштарак сәеррәк тоелса да, соңыннан инде ул телне шулчаклы хуш итәсең, татар дөньясын тасвирлаган андый эпик әсәрнең нәкъ шул татар иле телендә язылырга тиешлегенә инанасың.

Айдар ага – Татар теленең бөтен байлыгын, нечкәлеген тирәннән белеп, аның бөтен моңын, җанын аңлаган әдип. Ул дөнья халыклары телләре арасында татарыбызның изге АНА теленең иң камилләрдән булуын белә, аның бик күп телләргә нигез булганын әнә Уфадан Вильдан ага Фатхуллинның өйрәнүләре буенча, Европа телләрендә берничә йөз татар теле тамырлары, хәтта Америка индеецлары телендә дә зур охшашлыклар булуын белә.

Һәм Айдар ага шушы кешелек цивилизациясенең җәүһәрен саклап калыр өчен мәйданнарда ачлык тотты, кыйналды, кагылды, йөзләгән, меңләгән чыгышлар ясады, ачык һәм ябык хатлар язды – күп тапкырлар Россия Федерациясе Президентына; бәлкем шулай милләтебезне саклый алырбыз дип бер утрау «сорап», Норвегия короленә, милләтләрне бетерүгә каршы Патриарх Кириллга һ.б. Чөнки ул белә: Аллаһы Тәгаләбездән татар милләтенә иңдерелгән бу изге ТЕЛ һәм без аны сакларга тиеш!

Айдар аганың күзе – ялангач сыркыган татарлык җаны, татарлык рухы белән тоташкан булыр. Шуңа да аның күрмәгән әйбере, җитмәгән җире, кысылмаган нәрсәсе, кермәгән тишеге юк... Аның Иҗаты һәрвакыт Гамәлләре белән бергә бара. Шуның бер үрнәге булып «Хунвейбин» роман-эпопеясе тора.

Юкка гына бездә шагыйрь – Шагыйрь генә түгел, җаны белән язган язучы – Язучы гына түгел!

PS. БИКТЫРЫШ АЙДАР ХӘЛИМ – Татарстан Республикасының быелгы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә иң лаеклы иҗади, көрәшче шәхесебез! Аның иҗади хезмәттәшләреннән хөрмәт белән үтенеп сорар идем: «Айдар агадан соң гына», – дип, бердәм булып чыгарыгыз шундый карарыгызны.

Тар күңелләләр — без түгел ул

БАШЫ 3 НЧЕ БИТТӘ

Татарча сөйли торган радионы, ни уйлаптыр, «Болгар радиосы»на әйләндергән (җитмәсә аны «һәр татарның йөрәгендә» дип ышандырмакчылар) эфир әфәнделәре дә берәүнең, «фатирны бер җыр җырлап түгел, утыз ел заводта эшләп аласы аны», дигән сүзләрен яңгыраттылар. Карагыз әле, милләттәш әфәнделәр-ханымнар, хакимиятнең үз талантларыбызны вакытында «күреп алмавыннан» гел зарланучылар, татар кешесе кылган олы эшләрнең һәм зур батырлыкларның хак бәя алмавына еллар буе әрнүчеләр без түгел идекме соң?! Сүз бит нindидер Латин Америкасы сәнгать йолдызын «үпәчләп», аңа беркайчан кирәк булмаячак кыйммәтле бүләк тапшыру хакында бармый. Бу очракта безнең хакимият безнең талантлы кызларны матур уңышлары белән тәбрикләп бүләкли. Аерма зур ләбаса. Хәзер инде бушлай фатирны заводта утыз ел эшләүчеләргә дә бирмиләр, ләкин моңа әлеге ике сеңел һич кенә дә гаепле түгел. Дөресен әйткәндә, завод-фабрикаларда, төзелешләрдә эшләргә теләүчеләрнең хәзергедәй азаюы шартларында аларны фатирлар биреп тә кызыксындырмауларын мин дә һич ничек аңлый алмыйм. Киресенчә, акыллы хакимият бу мәсьәләгә кабат әйләнеп кайтырга мәҗбүр булыр, мөгаен, чөнки арзанлы эш көчләрен гел читтән генә китерә алмас, дип уйлыйм. Ә безнекеләр безнекеләрнең кадерен белсен. Менә милләттәшебез Гази Заһитов батырлыгының үз бәясен алмавы кайчаннан бирле җаннарыбызны сыкрата. Әле узган ел гына да Россия телевидениесенең Бөек Җиңүгә багышланган ниндидер бер тапшыруында фашизм өстендә тәүге Җиңү байрагын җилфердәтүчеләр дип әлеге дә баягы рус Егоров белән грузин Кантария фамилияләре генә аталды, ә Рейхстаг түбәсенә иң беренче байракны элгән татар Гази Заһитов телгә дә алынмады. Безме шуңа җаныбыз көймәгән?! Бөтен өмет – үз җитәкчеләребездә. Динә белән Эльмирадай, Алсудай, Илһамдай чын тавышлы җырчыларыбызны да, халыкка игелекле бизнес хуҗаларын, дәвалый белгән табибларны, авыру балаларны чит илдә үз акчасына дәвалаткан мәрхәмәтле байларны да, яхшы күңелле юл-патруль хезмәте инспекторларын (бервакыт дәүләтебез җитәкчесе аларны «шоферларга җәза бирүче түгел, булышчы булачаклар» дип вәгъдә иткән иде), вазифасына тугры укытучыларны, лаеклы фән эшлекләләрен, төрле һөнәр осталарын, «үз чыгымнарыбызны кыскарту исәбенә, берничә айга, бер елга булса да бәяләрне арттырмый торырга булдык» дип белдергән газ, энергия хуҗаларын да, ит-сөт, икмәк җитештерү алдынгыларын, әдәбебез сагындагы әдипләрне, оста төзүчеләрне, хокук сагында гадел эшләүчеләрне, күмәк эшләп табылган акчага гаиләсе белән балдамайда йөзүгә, алтында коенуга вөҗданы җитмәгән башлыкларны да вакытында күреп, халык алдында хуплау сүзләре әйтеп торсыннар әйдә, шәп бит инде бу. Бер хуплансалар, хуплауга лаеклылар күбәячәк кенә бит. Үз күңелләребезгә дә бер багыйк әле: ул кадәр үк тар карашлылар һәм караңгы чырайлылар түгел ич без.

...Динә белән Эльмира исемнәре күпләр телендә тибрәлгән көннәрдә дә, аннан соң да «ТНВ» каналының «Музыкаль каймак» тапшыруын башыннан азагынача карап барырга тырыштым, чөнки әлеге ике җырчыны да ничектер күрсәтеп алырга, «каймаклар» арасына кертергә җай тапмый калмаслар, шәт, дип көткән идем. Ләкин яңа тапшыруларда да ел буе болгатылган иске каймаклары гына күренде, ә «Голос» бәйгесендә илкүләм иң күп тавыш җыеп җиңгән ике сеңел ичмаса телгә дә алынмады. Әйе, монысы да безнең асыл сыйфат, безнең чынбарлык...

КАЛӘМЛЕ ГАЛӘМ

ЛӘБИБИ ФИКЕР

Моннан ярты ел чамасы элек, бер танышымның улы белән кызы, үз эшләрен ачып җибәрмәкче булып, банктан бер миллион (!) кредит алган. Билгеле, үзләрен гаять белдеклегә санап, болар атаана белән киңәш-табыш итешеп тормаган. Аңлашылганча, бик тиз байыйсы килгән бу ике бертуган «эшмәкәр»нең. Әмма һәрвакыт син теләгәнчә генә булмый шул. Бездәге кәгазь бюрократизмы чабуыннан бер эләктерсә, бер адым да алга атлый алмыйсың. Болар да, озакка сузылган мәшәкать баткаклыгына чумып, байтак вакыт бер урында «буксовайт» иткән. Өстәвенә, бу ике яшь сантыйның анык һәм максатчыл бизнес-планы да булмаган, ахрысы. Кыскасы, «янганнар» бәхетсезләр.

Кабала

Банк билгеләгән сумманы түләү вакыты килеп җиткәч, бу «эре эшмәкәрләр», әлеге әҗәтне каплау өчен, икенче банктан янә... бер миллион кредит алган!

Ахыр чиктә, «яңа эшмәкәр»ләрнең әти-әнисе, бу афәттән котылмакчы булып, башкаладагы өч бүлмәле фатирларын сатарга мәҗбүр булды. Бүгенге көндә гаилә, ярык тагарак янында калган хәлдә, бер сәләмә авылның алама гына өендә гомер итәргә тырышып ята. Түлисе әҗәтләренең очы-кырые исә бер дә тиз генә күренергә охшамаган...

Үзем дә, моннан ике ел да ун ай элек, чарасызлык китереп кыскач, биш елда түләп бетерү шарты белән (җитәрлек акчаң булса, бурычыңны алдан каплап куярга да була), бер банктан әҗәткә шактый гына акча алган идем. Хәзер шул банкка ай саен биш мең ярым түләп барам. Хезмәтемә тиешле әҗерне вакытында ала алмау сәбәпле, чираттагы айлык бурычымны ике көнгә соңарып (шуның өчен тәмам пошаманга төшеп!) түләргә туры килде.

Түләвен ничек тә түлисең инде – кая барасың. Әмма түләгән чакта бернәрсә һәрвакыт аеруча эчне пошыра (йөрәкне кимерә, күңелне тырный, бәгырьне ашый... дип кенә хәл җиңеләйми, әлбәттә), ул да булса – процент акчасының син түләргә тиешледән бик күпкә артык булуы. Әйтик, ай саен 5555 сум (төрле банкта төрлечә) түлисең ди. Шуның өч меңе... банк файдасына! Нәкъ вакытында түләп баручы бездәйләрдән, банкның зур процент белән шулкадәр акча каеруы аңлашыла кебек. Әмма моның төбендә тагын ни-нәрсә ятканын күпләр белми дә торгандыр әле. Банк тәк торганнан акча өләшеп ятарга ул хәтле җүләр түгел. Аның һәр тиене – исәптә. Мин әйткән әлеге өч меңгә бурычларын банкка кайтару хәлләреннән килмәгәннәр белән әҗәтләрен кире бирү турында уйлап та карамаганнар өчен дә түләү кирә. Күңелне иң әрнеткәне – «җилгә очып киткән» менә шул процент акчасы да инде. Әмма терсәк якын да, тешләп кенә булмый. Сыкрап-сыктап шул акчаны түлисең дә, аннары үзеңне юаткан буласың: машинада җилдерәм бит әле, дисең. Мебель алып җибәрдек, ичмасам, кеше килсә – оят түгел, дигән буласың. Фатирны рәткә китердек, дип сөенәсең. Бераз булса да чәпчеми торыр, хатынымны тунлы иттем әле, дисең. Эшең дә бар кебек үзе, шөкер, тик менә хезмәт хакың гына – ташка үлчим (ә бит кешечә яшисе килә, нәгъләт!)...

Соңыннан үкенәбез дә үкенүен, ләкин тәбедәге сырга барыбер кызыгабыз шул. Коточкыч дәрәҗәдә арттырып түлисен дә беләбез югыйсә, әмма күрә торып кабалага төшәбез.

Бер дустым, күпчелегебез шикелле, һаман акча җиткерәлми интегә. Даими рәвештә матди кыенлык кичерүенә карамастан, хәленнән килгәнчә, банкка булган бурычын капларга тырыша үзе: каян да булса акча табып, әледән-әле пеня (латин сүзе – poena – җәза) түли. Банк белән үзара килешкәннәрдерме, юкмы, анысын белмим, әмма кредиты, моннан биш ел элек ничә сум алган булса, әле дә шул килеш тора.

Безнең нәсел – нык нәсел! Бәхетле ата – Габдрахман ага Фәйзуллин (уртада) һәм аның уллары – Рафаэль, Равил, Рөстәм, Илдус, кызы – Люция. 29 декабрь, 2007 ел.

Фото Л.ЛЕРОН архивыннан алынды

Кемгә ничек

Хикмәтле шигырьләр

Марат КӘРИМОВ

Берәүләргә хаклык –
түшәм кебек,
Түшәм ныклы икән –
бул тыныч.
Ел-яңгыр да сиңа
тими үтәр,
Бураннар да булмас
куркыныч.

Ә берәүгә хаклык –
идән кебек,
Шунда басып йөри
һавалы.
Шак-шок итә пычрак
итекләре,
Ул итекләр корыч
дагалы...

1986

Шигъри хәтер

ИДЕЛ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

Равил Фәйзуллинга

Дулкыннарың сугылалар килеп,
Алар, бәлки, хәтер сагында...
Син коточкыч чит шул миңа, Идел!
Син коточкыч миңа якын да.

Ерак әбием керен чайкагандыр,
(Туры килә безгә сыгарга!)
Коенырга дип кереп киткәндер дә
Оныткандыр кире чыгарга.

Әллә җилләр киереп атканмы аны
Ярдан читкә, сазлык-салкынга...
Син коточкыч ерак миннән, Идел!
Син коточкыч миңа якын да.

Ничә төннәр инде алтын балык
Төшләремә кереп йөдәтә.
Кара сулар туйдырдылар мине,
Каршы йөгер, Идел, йөрәккә.

Дүрт гасырлык сагыну бу сине, –
Әйдә, кемдер калсын пошаман.
Безнең якта арбалар да хәтта
Көймәләргә шундый охшаган.

Үткәннәре, киләчәге өчен
Мин ярлыкау сорыйм халкыма.
Син коточкыч ерак бездән, Идел!
Син коточкыч безгә якын да.

Туган көннәрен гел истә тотыйк,
Барчасын да, әйдә, бергә котлыйк!

29 гыйнвар (1961) –
Мансур ГЫЙЛӘҖЕВ,
драматург.

1 февраль (1957) –
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,
шагыйрь, прозаик.

2 февраль (1960) –
Салават ЮЗЕЕВ,
шагыйрь, прозаик, драматург.



Әҗәттән котылуның юлы бер генә – аны алмау.

Бибәл Норел

МИН ДӘ ЯЗДЫМ КӨНДӘЛЕК

(Әдәби фонд директоры язмалары)

1 октябрь, 1987 ел

Көн чалт аяз бүген. Кояш яктысы тәрәзә пыяласына ябышып каткан. Суыкның да суыгы – хәтәр! Тамак төбе үзен сиздереп тора – бер як өлеше ярыйсы гына шешкән...

* * *

Разил абый Вәлиев – Мәскәүдә. Хастаханәдә. Соңгы тапкыр Чехов базары янындагы обком хастаханәсе бакчасында (Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла һәм мин килгәнне белеп, шунда чыкты) күргәндә хәле яхшыдан түгел иде. Үзе сиздермәскә тырышты тагы. Шаярып-көлеп сөйләште. «Язмыш Мәскәүдә хәл ителә», – дигән иде диюен. «Монда кереп, хушлашкан кебек чыгып китте», – дип сөйләнеп торды берлек хезмәткәре Маһирә ханым. Чире чигенсен инде берүк, терелеп кайтсын тизрәк, дип телибез барыбыз да.

* * *

Кызыбыз Айсылуны Волков урамы чатындагы балалар бакчасына бирергә исәп. Бүген, шул бакчаның мөдирен күреп, сөйләшеп кайттым:

– Кызыбызны октябрьнең егермеләрендә йөртә башларбыз инде. Әлегә бездә «капремонт», – дидем. Нигә «капремонт» дип әйткәнмендер – белмим. Язучылар берлеге ишегалдындагы бер кумырыкта чиләнеп ятканыбызны исәпләмәгәндә, безнең җүнлебашлы торыр урыныбыз да юк бит әле, прописка хакында әйтмим дә...

– Пожалуйста, пожалуйста, – диде мөдир – марҗа ханым.

Көн кадагы

16 гыйнвар көнне күренекле язучы-прозаик, күпсанлы фантастик әсәрләр авторы, тел һәм мәдәният тарихы белгече, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты (2006), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Адлер Камил улы Тимергалин вафат булды. Җәсәде туган авылы Иске Минзәләбаш (Сарман) зиратында җирләнде. Мәрхүмнең җидесендә аның рухына багышлап Коръән укылды.

* * *

Шушы көннәрдә «Казан утлары» журналында (№ 1, 2013 ел) Башкортостанның халык шагыйре, бик күп татар әдипләренең якын дусты Марат ага Кәримовның (1930) бер бәйләм шигыре дөнья күрде.

* * *

Язучы Ләбиб Лерон күптәнге ниятен тормышка ашыру белән мәшгуль: ул, өлкән дусты һәм остазы Мәгъсум Хуҗин (1930-2008) турында истәлекләр китабы туплап, аны төзеп бетереп, ошбу араларда Татарстан китап нәшриятына тапшырырга җыена.

* * *

Узган атна башында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинның «Мәңгелек мизгел» дигән яңа шигъри китабы татар һәм рус телләрендә басылып чыкты.

Л. ЛЕРОН фотосы

«Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы житәкчесе Ирек Миңнәхмәтов яңа гына табадан төшкән китапны авторның үзенә – шагыйрь Равил Фәйзуллинга тапшыра.

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде

ЮБИЛЕЙ ИЛӘ

Язучы Госман Гомәр әдәбият сөючеләргә маҗаралы сюжет кору остасы буларак таныш. Сугыш чоры баласы буларак, аның кырыс чынбарлыгын, әти-әнисен югалткан ятимнәрнең ачы язмышын сурәтләүне дә читләтеп үтми ул. Кайбер әсәрләрендә исә яшьләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр тасвирлана, чын мәхәббәткә мәдхия җырлана.

Госман ага күптән түгел генә үзенең гомер бәйрәмен – сиксән яшь тулуны билгеләп үтте. Аны юбилее белән ихластан котлап, саулык-сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән мөбарәк озын гомер һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!

Редакция

Госман ГОМӘР

Аулак өй

(«Чия чебене» повестеннан өзек)

Бездәге аулак өйләрдән, кич утырулардан башларгадыр, бәлки, хикәятне. И-и, ул аулак өйләр! Хәзерге буын белми инде аны. Тәтеми ул аңа. Аңа әнә урам. Исерек урам. Сугышлы-үтерешле урам. Безнеке сөю тулы мәхәббәт урамы иде.

Сугыштан соң да әле, нинди авыр, ачлы-туклы көн күргән заманнарда да аулак өйләрнең кадерен, тәмен белеп, мәхәббәтнең самимилеген татып яшәдек.

Клуб бар иде анысы, һе, ник булмасын. Егет-җилән башта шунда җыелабыз: домино сугабыз, шашка уйныйбыз, гәҗит укыйбыз. Аннары бер тирә яшьләр, авылны урам-очларга бүлеп, аулак өйләргә таралышабыз. Эзлибез әле – кызлар кемнәргә җыелган бит. Арада белүчеләр бар, әлбәттә. Тик алар серне ачып бетермиләр, «килкиләр»дән яшерәләр. Кечерәк яки әле сөйгән кызлары булмаган малайларны шулай атыйлар. Бичаралар, тәмам күшегеп, өйләренә ычкынырга мәҗбүрләр. Кышкы төн аеруча салкын. Ул чакларда суыклык 35-40 градус тирәсендә торды. Шулай ук кайры тун киеп йөрүчеләр дә сирәк, электән хәлле саналган гаилә малайларында гына. Андыйларның әтисе йә авыл түрәсе, йә шул тирәдә боргаланучы адәмнәрнеке. Ә безнең өстә юка бишмәт, күбебездә тән җылыткыч сырма. Итекләр тишек, үкчәдән олтан урынына тутырылган салам тырпаеп йөри. Тунлы малайлар «ялгыш» кына салам учмасына китереп басу белән – «олтан» суырыла да чыга, кып-кызыл үкчә күренеп кала. Өеңә йөгерми хәлең юк. Чаңгы кебек каткан чабаталы малайлар чыдый, тишек итеклеләр кача. Хәзер кызык инде, Гайсә абый. Элек оялмаган да, түзгән, чыдаган.

Төн суык, дидем, ә йөрәкләр кайнар. Серле мәхәббәт кайнарлыгы җылыта. Без менә шундый идек!

Сөяк эзләгән маэмай шикелле, йөрибез урам буйлап. Тәрәзәсе калын боз белән капланган бер йортта бишле лампа яктылыгы шәйләнә. Беләбез, кызлар безне көтә. Әкрен генә тәрәзәгә чиртәбез. Эчтә ут сүнә. Имеш, йокларга яттылар, бимазалап йөрмәгез, янәсе, һе, кызларның яраткан уены инде бу. Ә беләселәре килә: тәрәзә артында кайсы оч егетләре икән? Аның Габдулласы, Сәлиме бармы төркемдә? Уч төпләре, кайнар сулыш тәрәзә бозына «бәке» тишә. «Кара, берәү дә юк ич анда», – ди күзләүче кыз. «Посканнардыр әле, ут яндырганны көтәләрдер», «Кайсылары икән соң?!»

Төн кошлары инде ишек төбендә, сак кына шакып куябыз.

– Кем бар анда?

– Без идек.

– Йомышыңны әйт тә кит.

– Җылынып кына чыгыйк инде?

Өйалдына ачы теллеләре чыкса, бер дә кызганып тормый.

– Кайтып, әниең куенында җылын, – ди пырхылдап.

– Минем синең куенында эрисем килә.

– Котсыз нәрсә.

– Котым очты, әнә Сабира апайларның капка башына барып кунды.

– Катырып үтерәсез ич инде. Саҗидә, җанашым, иртәгә сулы чиләкләреңне тау башына үзем менгереп куярмын.

Әкрен генә келә күтәрелгәне ишетелә. Кыз бер почмакка посып кала. Имештер, ишекнең ачылуында аның бер гаебе дә юк. Салкын һавага уралып, өйгә кереп тулабыз. Бишмәтләребезне мич артына томырабыз, үзебез эскәмияләргә тезелешәбез. Кызлар сәкедә, итәкләрен җәеп, кулъяулык чигәләр, йомгакларын сүтә-сүтә, егетләренә йон пирчәткә бәйлиләр. Сүз төрттерү китә.

– Борының өшегән бит, Сәлимҗан, у тизрәк.

– Синең иннек кирәк аңа, Маһибәдәр. Битеңә бер пот итеп сылагансың, хәерсез. Калмадымы бераз?

Маһибәдәр нишләргә дә белми, янындагы ахирәтенә борыла.

– Бир тизрәк көзгеңне. Абау, кызлар, күбрәк киткән ич. Бисплатный. Кичә Сәлимҗан бүләк иткән иде.

– Алырсың ул каруннан. Җавап мәгънәле булыр.

– Чикләвек челтерәмәгәч, кесәдәге тишектән иннегә төшеп калган, пудрасын җил тузгыткан.

Бездә кызлар чикләвегенә каршы иннек, пудра, брошка, кайчакларда кәнфит-фәлән бирү гадәте бар. Сәлимҗанның җавабы шуңа ишарә. Әмма кесә такырлыгы бу йоланы уптым гына үтәргә мөмкинлек бирми. Үтәлгән тәкъдирдә дә, бер-берсен сөйгәннәр өчен яшерен сер булып кала анысы.

Иннек «ягынып», кәнфит белән «сыйланып» алгач, беразга тынлык урнаша.

– Фатыйх, ул тубалың чебеш чыгармый микән инде?

– Әле күкәй генә сала, ди.

Гармунчы Фатыйх көндәге сүзләрен кабатларга мәҗбүр.

– Салкын бит. Җылынып җитмәсә, теле ябыша, диләр сиңа. Ә сезнең тел исә тәмам чарланып беткән.

– Күрче, гармуны урынына үзе сайрый бүген. Бик ялынганнар ди.

Кызлар гармунсыз гына җырлый.

Кара туры
атларыңны
Җигәсең дә китәсең;
Шул гадәтеңне
яратам –
Сагынып килеп
җитәсең.

Аннары егетләр аваз
сала.

Кара дугалар
килешә
Баш күтәргән
атларга.
Ал чәчәгем дияр
идем,
Карамасаң ятларга.

– Әйдәгез, арка сугышлы уйныйбыз.

– Әйе шул, Фатыйхның чебешләре үсә торсын.

Сәке йөзлегенә төшеп утырган кызның алдына иң таза егетләрнең берсе башын яшерә, кулын аркасына куя. Чалт берне!

– Син.

– Кире ят.

– Бу юлы син менә.

Кем сукканын белгәнче тинтерәтәләр егетне. Хәйран гына шапылдаталар, куллары кызарып бетә. Ниһаять, кызлардан берсе килеп каба. Аңа йомшаграк итеп чәпиләр. Катырак төшсә, шунда ук аваз сала:

– Абау, кулың, тол кызга өйләнерсең әле. – Кыз булгач – тол, тол икән – кыз булмый ич инде ул. Ярый миңа кайсы да.

– Яраса, ят әйдә. Тирләтик әле шуны, кызлар!

Монда кемнең кемгә ничегрәк төшерүеннән дә бөтен нәрсәне чамаларга була. Әйтик, чираттагы җәзага тартылган егеткә бер кыз чебен кугандай гына чәпелдәтеп алды ди. Белә егет кем сукканын, юри икенче берәүгә сылтый. Тагын ят! Кыз, канатларын җәеп, башкаларны киртәли дә уч төпләрен уып куя. Үзем, янәсе. Чәп тагын берне, җаныкаем! «Белми» инде, һе! Шул рәвешле дәвам итә – кыз тотылмый. Икесенә дә рәхәт. Башка берәү кулы төшкәч кенә туктала болар арасындагы мәчетычкан уены. Чын җәза алучыны «тәмләп-тәмләп» җәфалыйлар аннары.

Ниһаять, «чебешләр» борынлый башлый. Фатыйх, телләренә басмыйча гына, гармунын гөж-гөж китереп ала – тубалның эченә җылы һава тутыра. Кызлар гына тубал дип үрти. Фатыйхның унике клавишалы, җиз телле тальянкасын тирә-як авылларда да яхшы беләләр. Ник димәктән, кичке уенда бер тартып җибәрсә, бөтен Иж буе моң белән тула. Рас әйтәм, һе! Әрәмәлекләрдәге кошлар да тынып кала. Безне уздыручы нинди моң бу, дияләрдер, бәлки.

Фатыйх – заманында авылның атаклы гармунчысы саналган Шакир абый малае. Гармунда уйнарга улын өйрәтеп маташмаган. Фатыйх өч яшеннән үзе гармунга ябышкан. Сәке астына кереп утыра да, телләргә басып, «Баламишкин»ны «чүпли» икән. Тора-бара сыздырып уйнап ук җибәрә. Күрше авыл сабан туйларына баргач, егетләр, бер генә кич бездә кунып китсәнә, дип ялваралар аңа. Ул уйнамый да кебек, телләр өстендә нәзек бармаклары гына йөгерә, гармуны үзеннән-үзе сайрый. Кызларны җилкендерә белә Фатыйх. Җыр артыннан җыр китә.

Кызыл-кызыл бөрлегән
Күл читендә тезелгән.
Булмас инде минем кебек
Синең өчен өзелгән.

Әйдә, дустым, су буена,
Бөдрә чәчең юарсың, –
Син юарсың, мин
җырлармын,
Күңелең тулса, еларсың.

Егетләргә дә җыр тыңлап кына утырырга димәгән, һе! Ут чыгарып биләр. Ә, алай икән! Кызларга да чират җитә. Теге яки бу егетне аяктан егабыз дип, биергә керешәләр – ярышып тыпырдаталар. Арыгач, түгәрәк ясап, биюне җыр белән аралаштырып дәвам итәләр. Кулларның кайнарлыгы, йөрәкләрнең ялкыны шул чакта сизелә инде. Әгәр берәр кыз кулыңны кысыбрак тотса, ул төнне күзләреңнән йокы качасын белеп тор. Бу инде тизрәк «йөзек салыш», «йолдыз санау» уеннарын башларга сәбәп була.

Менә «йөзек салыш» уены башлана.

Һе, ул йөзекне әйтәм әле. Бүген кызлар киеп йөри торган кызыл, зәңгәр, яшькелт кашлы алтын яки көмеш йөзек түгел – ә сабы сынган алюмин кашыктан чүкеп ясалган. Кашык сабын түгәрәкләп кисеп аласың да, тимергә кигереп, сак кына чүкисең – ун-унбиш минуттан йөзек әзер. Аны мич алдында, кирпечкә ышкып шомартасың, итек яки оек балтырында ялтыратасың. Рәхәтләнеп кия бир. Кызларның һәр бармагында берничәшәр шундый бизәк була. Бер-икене егетләр дә кия. Әлбәттә инде, баерак әби бәйрәм-сәйрәмнәрдә сөекле оныгына чын йөзеген – алтын яки көмештән коелганын да биреп торгалый. Безнең уенга алюмин дигәне дә бик бата.

Сәке йөзлегенә, гомер узу белән саргаеп, шомарып беткән эскәмияләргә тезелеп утырабыз. Уртага, йөзеген тотып, бер кыз чыга. Фатыйх «Әпипә»не сайрата. Кыз биеп, безнең учларга йөзек салгандай кылана. Туктап, кулларын чәбәкли:

– Йөзек кемдә – йөгереп чык!

Учында «сер саклаучы» сикереп уртага чыга. Ә бит күршесе аны тотып калырга тиеш иде. Әләктерсә, йөзек иясе җәза ала. Җаны теләгән егет яки кыз белән өйалдына йолдыз санарга чыга. Суык көннәрне хуҗабикә тышка чыгып йөрергә рөхсәт итми, чөнки өй суына, почмак якка кереп утырырга гына кала. Анда нинди йолдыз санйисың инде. Әкрен генә биттән үпкәнеңә дә апаның мич башындагы малайлары пырхылдап көләргә тотына.

Ни дисәң дә, өйалдында аулак инде анысы, һе, салкынга гына түзәрләр анысы. Беренче елларны үзем дә, нәрсә сөйләшәләр икән шултиклем, дип гаҗәпсенә идем. Гөлҗиһан белән йолдыз санарга чыга башлагач, моның серенә төшендем. Болай ул миннән ике яшькә олырак, абыйдан өч яшькә кечерәк. Бергә уйнап үстек. Каз бәбкәләрен сакладык, бозау арканларга йөрдек. Ничектер аерылмас дуслар кебек идек. Кич утыруларга чыга башлагач, бөтенләй ычкындык – яхшы мәгънәсендә әйтүем. Әллә ни булды шунда. Сиздерми генә йөрәкләребездә ут дөрләде, мәхәббәт уты! Яшьлектә кабынган ялкынны бернинди өермә-давыллар да, көзге яңгырлы, ачы җилләр дә сүндерә алмый икән – без моны үз язмышыбызда татыдык.

«Йөзек салыш»та, җәзаны юри үзебезгә алып, йолдыз санарга ешрак чыга башладык. «Тегеләр ни сөйләшә икән?» дигән сорауга җавап та табылды!

– Тәки белмәдең мин сукканны, – ди Гөлҗиһан.

– Синмени ул май белән сылаучы! Кулларың шулчаклы йомшак, мамык кебек, ипидер менә.

– Учларым кызарып бетте. Менә тотып кара, нинди кайнар.

Чыннан да, Гөлҗиһанның куллары ут кебек. Кайнарлыгы йөрәгемне өтә, кызны кочагыма ныграк кысам. Шулай, сүзсез-гамьсез бик озак утырабыз, йөрәкләребез генә сөйләшә. Эчтәгеләр көтеп көтек булганнардыр инде. Ни гәпләшә болар, дип аптырыйлардыр. Безгә аларсыз да рәхәт.

Хәер, арабызда сүз эзләп кесәгә кермәүче егет-кызлар да җитәрлек. Озаграк торуның җаен-әмәлен табалар. Имеш, алар да төшеп калганнардан түгел, бу дөньяның рәтен беләләр. Бер-берсен ошатсалар – бигрәк тә! Егет сүз ката:

– Малай, сыер бозаулады бит әле безнең.

– Кайчан?

– Узган төн.

– Саклагансыздыр инде.

– Исебез дә китмәде.

– Тиленәр!

– Ник?

– Ник буламы? Чүбен ашаса соң?! Угызыннан колак кагасыз ич. Җәй буе сөтен эчә алмыйсың – ислегә әйләнә.

– Син үзең юләр. Безнең әби бар бит.

– Хи-хи-и, көлдермә, яме! Шәмсия әби үзе бозауладымы әллә?..

– Тагын юләр сүз. Андый чакларда йорт иясе уята безнең әбине. «Шәмсия, тор!» – ди икән. Йә прәме: «Сыерың бозаулады», – дип уята. Кайбер елларны бозау булып мөгри. Фонарьны кабызып чыгабыз, чыннан да, сыер бозаулаган, сарык бәрәнләгән була. Аннары чүбен саклыйбыз инде. Син әйткәнчә, ашатырга ярамый.

– Соң, баштан ук шулай диләр аны. Шәмсия әби бик әйбәт карчык бит ул сезнең, шуңа яратадыр йорт иягез.

Кичтән чаналарны карап, әни белән урманга иртәрәк китү турында сөйләшәбез... – Иртән, таң атар-атмас, әби уята: «Торыгыз, хәбәр бар, вакыт җиткәндер», – ди. Шуннан аңлыйбыз инде нинди хәбәр икәнен. Кичтән без сөйләшкәннәрне, күзгә күренмичә генә, йорт иясе янибызда тыңлап йөргәндер инде.

– Кызыгам мин сиңа, Сәлимҗан!

– Кызыксаң соң, әйдә, йөрибез, Маһибәдәр! Вәгъдә бирешик шушында. Беркемнән кыерсыттырмам үзеңне, ипидер!

– Туңдырып үтерәсең инде.

– Кер минем бишмәт эченә!

Тышта Сәлимҗан белән Маһибәдәрдән дә озак торып кергән кеше булмый бу кичтә. Аларның йөрәгенә ут үрмәләгәнен башкалар да сизә, билгеле.

– Күктә йолдыз калмагандыр, безгә дигәнен дә чүпләгәннәр болар.

– Сәлимҗаны сунарчы ич, урманга куян атарга алып баргандыр.

– Кара калтыравын гына Маһибәдәрнең. Үзе көлгән була тагын, – дип битәрлиләр кызны.

– Гөлҗиһанны бер дә күрмисез, – ди Маһибәдәр, ахирәтен кысып кочаклап. Бүгеннән башлап алар сердәшләр. Шулай булмыйча, икесе дә егетле кызлар ич хәзер!

Аулак өйләр таныштырды, кавыштырды күбебезне. Бөреләнгән мәхәббәткә очар канатлар куйды, аны җил-давылда сынап ныгытты. Аерылышулар юк та кебек иде ул елларда. Булса да сирәк очраганда, җитди сәбәпләр аркасында, бәлки...

«Японијәдә татарча сөйләшеп йөрдем»

Бүгенге яшьләр арасында вакытларын бушка уздырмыйча, аның кадерен белеп яшәүчеләр шактый булуы күркәм күренеш. Казан театр училищесының 2 нче курсында белем алучы Идел КЫЯМОВ – нәкъ шундый тырыш егетләрнең берсе. Ул үзен моннан ике ел элек шәһәрдә уза торган «Татар егете» бәйгесендә беренче урынны яулап таныткан иде инде. (Идел үзенең тырышлыгын Яшел Үзән районының Шырдан авылында яшәүче әбисенең тәрбия нәтиҗәсе дип саный.) Моннан берничә ай элек ул Японијәгә барып, анда фотомодель булып эшләп кайтты. Бүген Идел үзенең чит илдән алган тәэсирләрен безнең белән дә уртаклашты.



СӘЯХӘТТӘН СОҢ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Идел, фотомодель эше белән ничек кызыксына башладың? Әллә берәрсе тәкъдим иттеме?

– Әлеге эш белән 2010 елда мавыгып киттем. Бервакыт Модельләр агентлыгына барып карадым да, анда берничә дәрес үтеп, үзем генә ирекле шөгыльләнә башладым. Фотоларымны тупладым да интернетка куйдым. Шуннан соң, бер чит ил агенты «үзебезгә алабыз» дигәч, бик теләп ризалаштым.

– Укуыңны бер айга калдырып, анда баруыңа үкенмисеңме? Андагы эшчәнлегең хакында да сөйлә инде.

– Бер ай дәрес калдырсам да, беренче семестрны гел «биш»ләргә тәмамладым. Модель булуыма бик шатмын. Японијәдә Җир шарының төрле почмакларыннан килгән яшьләр белән аралашу үзе ни тора бит. Миңа калса, бу бик кызык эш. Без Токиода төрле журналлар һәм каталоглар өчен фотога төштек.

– Японијәдә синең өчен иң истә калганы нәрсә булды?

– Иң истәлеклесе – үземә япон дустымны таптым. 21 яшьлек Юта Хишияма белән татарча гына сөйләшеп йөрдек. Ул татар телен үзләгеннән өйрәнә икән. Үзе укый торган университетта «Татар әлифбасы» дигән темага диплом эше яклаган. Хәзерге вакытта аспирантурада белем ала.

– Татар теле аны ничек җәлеп иткән?

– Ул интернетта «Аерылмагыз» дигән җырның клибын күреп алган. Шуннан соң, мәгънәсен беләсе килеп, татарча өйрәнә башлаган. Японнарга да киләчәктә татар телен өйрәтергә тели. Быел Казанга кунакка да чакырдым үзен.

– Токиода сине иң гаҗәпләндергән нәрсәләр...

– Әгәр Японијәдәге үсешне безнең илнеке белән чагыштырсаң, үзебезнең күп елга артта калуыбызга инанасың. Анда бөтен нәрсә автоматлаштырылган. Машинистсыз гына йөри торган өчәр вагонлы электричкалар да минем өчен кызык тоелды. Японијәдә өлкәннәрне хөрмәт итү көне бар. Һәр шимбә көнендә Гинза дигән районда урамда берминди транспорт хәрәкәте булмый. Шунда халык гаиләләре белән ял итеп кенә йөри. Машиналар катлы-катлы юллардан җилдерә. Анда халык өчен бөтен нәрсә уңайлы. Бөкеләр дә юк. Шулай ук мәчетләре белән дә кызыксындым. Аны 1917 елда төрекләр ярдәме белән революционерлар төзегән булган. Узган гасырда мәчетне берничә тапкыр төзекләндергәннәр. Андa да кереп чыктым. Намазга килүчеләрдән тыш, аны японнар да каpарга килә икән. Шуңысы кызганыч, театрларына билетлар кыйммәт булу сәбәпле, керә алмадым. Билет бәясе бездәге акча белән 1 мең 500 сум тора. Андагы хезмәт хакы өчен ул зур акча түгел, билгеле. Мин дуслашкан Ютаның әтисе журналист булып эшли. Ул, безнең акчага әйләндерсәк, елына 500 мең сум хезмәт хакы ала.

– Кибетләрдә йөргәндә иң элек ят булган азык-төлеккә күз төшүчән. Ике ай яшәү вакытында япон ризыкларын үз итәргә өлгердеңме соң?

– Килеп төшүгә үк үземнең мөселман булуымны һәм дуңгыз ите ашарга ярамавын әйтеп куйдым. Алар сүзгә колак сала торган халык. Ресторанда миңа тиешлесен генә китерделәр. Аннары үзем дә пешереп ашадым. Супермаркетларның берсендә хәләл тавык ите таптым. Анда колбасалар да күренми. Японнар үзләре аз ашый икән.

– Модельләрнең дә ашауларын чиклиләр түгелме соң?

– Андый таләп күбрәк кызларга куела. Гәүдәне тиешенчә тоту өчен, спорт белән дә шөгыльләнәм.

– Киләчәктә дә бу эшеңне дәвам итәргә уйлыйсыңмы? Аннары синең әтиең Илдар Кыямов та сәнгать кешесе. Үзеңне сәхнәдә нинди юнәлештәге артист итеп күз алдына китерәсең?

– Әлбәттә, әгәр тәкъдим булса, тагын берәр Европа иленә барып кайту теләге бар. Киләчәктә эстрада юнәлешендә, нәфис сүз жанры буенча эшләрмен, дип уйлыйм. Калган планнарымны әйтәсем килми әлегә. Аларны әйтсәң, тормышка ашмаска мөмкин.

– Әгәр үзеңә фильмда төшәргә тәкъдим итсәләр...

– Бик рәхәтләнеп ризалашыр идем. Минем инде Ленар Сәйфиев клибында төшкәнем бар.

– Яшьтәшләреңә җиткерәсе теләкләрең...

– Һәрвакыт үз максатыңа ирешү өчен көрәшергә кирәк. Компьютер яки телевизор каршында гына утырмасыннар иде. Һәркем зиһенен үстерсен.

Исеме дә затлы булсын

БЕЛМИ КАЛМА!

Университиаданың ачылыш һәм ябылу тантаналары үтәчәк 45 мең урынга исәпләнгән стадионга исем сайлау дәвам итә. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы сайтында ачык тавыш бируләрнең нәкъ менә кызган мәле. Исемнәр тәкъдим итү барган беренче тур тәмам инде. 25-30 гыйнвар көннәрендә беренче тур нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү бара. Әйтергә кирәк, тәкъдим ителгән исемнәр арасында иң еш очрый торганнардан иң яхшы 5 исем билгеләнгән инде. Һәркем тәкъдим ителгән вариантларның берсенә тавыш бирергә хаклы. Бәйгедә катнашучыларның географиясе бик киң булуын да әйтеп узарга кирәк. Стадионга исемне Татарстан халкы гына түгел, Россия төбәкләрендә һәм шулай ук чит илләрдә яшәүче кардәшләребез дә сайлады. Бәйгенең җиңүчесе стадионны ачу тантанасында кыйммәтле бүләккә ия булачак. Стадион исеменә тәкъдимнәр арасында Kazan-arena дигәне дә еш очрый. Әйтергә кирәк, әлеге исем Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да ошаган иде.

Стадион исеменә тавыш бирү нәтиҗәләре (28 гыйнварга):

Kazan-arena – 44 процент;

Зилант – 24 процент;

Миллениум – 14 процент;

Uni (Юни) – 9 процент;

Татарстан-arena – 9 процент.

Автоузышчылар ут уйнатты

Усад бистәсендә узган ял көннәрендә автомобильләр кар бураны туздырды.

СПОРТ

А-1600 төркемендә кышкы трек узышлары буенча Татарстан Республикасы Кубогының 1 нче этабында кискен көрәш барды. Казанның «Намус» спорттехник клубыннан Тимур Тимерҗанов җиңү яулады. Тимур – ралли-кросс буенча ике мәртәбә Европа чемпионы исемен алуга ирешкән тәҗрибәле пилот. Шулай ук «Намус» клубы исеменнән чыгыш ясаган Рәсүл Миңнеханов һәм Түбән Камадан Олег Жаворонков («Кама-Euro») узышны икенче һәм өченче вакыт күрсәткечләре белән тәмамлады. «Тимерхан» спорт клубы вәкиле Рөстәм Миңнеханов призлы урыннарны алучылардан секундларга гына калышты.

«Национальный» төркемендә трек узышлары буенча Россия Кубогының 1 нче этапларында Тольятти спортчыларына тиңнәр табылмады. «Лада МПС-мотоспорт» клубы пилоты Дмитрий Брагин – беренче. «Автоваз ПРОО» клубы спортчылары Павел Кальманович – икенче, ә Владимир Шешенин өченче булдылар. «Национальный» төркемендә трек узышлары буенча Татарстан чемпионатының 1 нче этабында «Кама-Euro» клубы вәкиле Рафаэль Фәттахов җиңүне үз кулыннан ычкындырмады. Аның клубташы Олег Жаворонков – икенче. Тимур Тимерҗанов, бу төр узышларда да тимер ныклык күрсәтеп, финишка 3 нче булып килде.

КЫҢГЫР ЭШ

Кондукторның кәефе ничек?

Казанда 49 нчы маршрут автобусының кондукторы белән бер пассажир арасында чыккан бәхәс якалашуга кадәр барып җиткән. «Восстание аермасы» тукталышында автобуска утырган пассажир кондукторга электрон юл йөрү билеты яткан акча янчыгын сузган. Валидатор анда калган акчаны күрсәткәннән соң, акча янчыгын кондуктор кулыннан кире тартып алу гына начар тәмамланган. Кондуктор, кызып китеп, пассажирга начар сүзләр әйтә башлаган. Өстәвенә, телефонын алып, аны фотога төшерергә керешкән. Аңа җавап йөзеннән пассажирның да шулай эшләве кондукторның ачуын тагын да кабарткан һәм инде алар сугышка ук башлаганнар. Әйтергә кирәк, пассажирга берәү дә ярдәмгә килмәгән. Аңа, бу бәхәсле автобустан төшеп, юлын икенче транспортта дәвам итүдән башка чара калмый.

Куллары кычыткандыр...

Вандаллар Казанның Карбышев тукталышы янындагы күпердә инвалидларны күпердән тукталышка күчерү өчен каралган лифтның пыялаларын ватканнар. Аларның инде мондый корылмаларны беренче генә ватулары түгел. Комаров тукталышыннан ерак түгел урында да шундый ук лифт җимерелгән.

Эш тапмасам, корал ясыйм

Казанның Мәскәү районы суды беркайда да эшләмәүче 36 яшьлек Дмитрий Чурихинны 6 ел да 6 айга иреге мәхрүм итәргә дигән карар чыгарган. Ир-ат, корал һәм наркотикларны законсыз әйләнешенә катнашы булудан тыш, ике тапкыр автомобиль урлауда һәм 22 тапкыр фатир басуда гаепләнә. Аның фатирында һәм гаражында булган тикшерү эшләре вакытында полиция хезмәткәрләре корал ясау өчен эшләнмәләр һәм кирәк-яраклар да тап булганнар. Әле аның төрмәдән азат ителүенә дә 2 ел гына узган икән. Эш таба алмый интерәп йөргәннән соң, ул идән асты бизнесы ачып җибәргән: соңыннан сатып акча эшләр өчен утлы корал ясый башлаган.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Без бергә булганда гына көчле!

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: «ТАТМЕДИА» ААҖ www.shahrikazan.com Реклама хезмәте телефоны: (843) 562-50-12

Шәһри КАЗАН

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы директоры – баш мөхәррир Мансур Газизҗан улы МОРТАЗИН

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: 420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Http://shahrikazan.com
E-Mail: shahri-kazan@tatmedia.com
ТЕЛЕФОННАР: 562-50-12 – кабул итү бүлмәсе, 562-50-07 (факс), 562-63-90 – бухгалтерия, 562-50-03 – хатлар бүлеге.
НӘШРИЯТ: «ТАТМЕДИА» ААҖ 420097, Казан, Академия ур., 2

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды.

БАСМАХАНӘ: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 17 сәгатьтә.

Тираж сертификацияләнгән.
Тираж – 3517 данә

Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк.
Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
© Газетада басылган язмаларны файдаланганда, шулай ук өзекләр китергәндә «ШК»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.
Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга
Заказ 29470
ИНДЕКСЛАР: 54126 (3 тапкыр чыга), 16076 (пәнҗешәмбе саны) 54207 (оешмалар өчен)
Сатудагы бәясе ирекле
12+